ӘРӘМ БУЛДЫ

Әтнәдә бруцеллез аркасында 5,5 мең баш терлек юк ителәчәк

> 5

НИЧЕК ЯШӘРГӘ?

ВИЧ-инфекцияле кешеләрнең тормышлары турында уйдырма һәм чынбарлык

> 7

ФИРЗӘР МОРТАЗИН:

«Бездә эстрада элек тә юк иде, хәзер дә юк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 177 (29144) | Җомга | 1 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

КЫЙММӘТЛЕ ЯҢА ЕЛ

БЫЕЛ БӘЙРӘМГӘ ӘЗЕРЛЕКНЕ АКЧА САНАУДАН БАШЛАРГА КУШАЛАР

Тагын бер айдан – Яңа ел. Җиң сызганып, бәйрәмгә әзерләнә башларга вакыт. Белгечләр быел бу эшкә мөмкин кадәр иртәрәк тотынырга киңәш итә. Иң беренче эш итеп... чыгымнарны һәм керемнәрне санарга кушканнар. 2024 ел – Яшел агач аждаһа елын каршы алу күпмегә төшәчәк? «ВТ» хәбәрчесе шуны исәпләп карады.

> 6

Ишетми калмагыз

Россия Президенты Владимир Путинның зур матбугат конференциясе 14 декабрьдә булачак. Быел ул «Туры элемтә» белән бергә үткәрелә.
Президентның матбугат секретаре Дмитрий Песков сүзләренә караганда, инде бүгеннән үк халыктан сораулар кабул итәләр. Дәүләт башлыгына телефон (8 (800) 200-40-40), сайт (москва-путину.ру) аша яки 04040 номерына смс-хәбәр юллап сорау бирергә була. Быелгы яңалык – чараны оештыруда Гомумроссия халык фронты катнашачак. Сорауларны алар җыячак. Ә инде Президентның халык белән аралашуы тәгәлләнгәннән соң, аларны эшкәртәчәк.

Быел гыйнвардан сентябрьгә кадәр Татарстанда уртача хезмәт хакы 59222 сум тәшкил иткән. Росстат мәгълүматларына караганда, узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда бу сан 18,1 процентка зуррак.
9 ай йомгаклары буенча республикада уртача хезмәт хакы күләме Идел буе федераль округының 14 төбәге арасында иң югарысы булып чыккан. Пермь крае (57561 сум) икенче урынны алган. Башкортстан – өченче (54712 сум).

Корылык аркасында быел Татарстанда ашлык уңышы 30 процентка кимрәк булган. 1 ноябрьгә, кукурузны да кертеп, барлыгы 3,7 миллион тоннадан артык бөртек җитештерелгән. Бу – узган елның шушы ук чорындагыга караганда 31,1 процентка кимрәк. Росстат мәгълүматларына караганда, республика – ашлык уңышы буенча федераль округта икенче урында. Чөгендер уңышы да (1,5 миллион тонна) узган елдагыдан 1,2 процентка ким. Бәрәңге 872 мең тонна (2022 елдагы уңышның 95,5 проценты) җыелган.

Декабрь башында Татарстанда юеш кар, буран, көчле җил көтелә. Көндез һава температурасы −10, төнлә −15 градуска кадәр төшәчәк.
Гидрометеоүзәк фаразына караганда, шимбә – 2 декабрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы 0…−7 градус күрсәтәчәк. Төнлә −4…−11 градус. Урыны белән юеш кар, буран, юлларда – бозлавык һәм кар көртләре. Якшәмбе – 3 декабрьдә көндез −5…−10 градус, төнлә −7…−12, урыны белән −15 градуска кадәр. Төнлә күпчелек районнарда кар явачак. Урыны белән томан төшәргә мөмкин.
Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, киләсе атна башында – 4–5 декабрьдә юеш кар, көчле җил, юлларда бозлавык көтелә. Дүшәмбе – 4 декабрьдә көндез −1…−6, сишәмбе – 5 декабрьдә −4…−9 градус булачак. Бозлавык, урыны белән кар көртләре. Республика Дәүләт автомобиль инспекциясе йөртүчеләргә юлларда сак булырга киңәш итә.

Районнарда ни хәлләр?

Әлмәт

Әлмәттә юл хезмәткәре боз астына төшеп киткән баланы коткарган. Башлангыч сыйныф укучысы шәһәр күлендә суга бата. Аңа ярдәмгә Әлмәтнең автомобиль юллары идарәсе хезмәткәре Руслан Сабаев килә. Бу хакта үзенең телеграм-каналында район башлыгы Тимур Нагуманов хәбәр итте. «Аның тиз арада ярдәмгә ашыгуы малайның гомерен саклап кала. Битараф булмавы һәм геройлыгы өчен Руслан Сабаевка рәхмәтемне белдерәм!» – дигән район башлыгы.
(«Әлмәт таңнары»)

Зәй

Быел район үзәк хастаханәсендә 2125 өлкән кеше һәм 9667 балигъ булмаган бала – профилактик тикшерү, 11033 кеше диспансеризация узган. Тагын 3894 кешене җентекле диспансеризация барышында тикшергәннәр. «2021 елның июленнән коронавирус белән авырган пациентлар өчен җентекле диспансеризация каралган. Чөнки коронавирус инфекциясе организмның барлык системасына тәэсир итә. Йөрәк-кан тамырлары һәм сулыш системалары ягыннан үзгәрешләр иң еш теркәлә», – ди район үзәк хастаханәсенең профилактика кабинеты шәфкать туташы Регина Галимова.
(«Зәй офыклары»)

Түбән Кама

Шәһәрдә «Түбән Кама гүзәле һәм батыры» муниципаль иҗат бәйгесенең финалы узды. Татар халкының милли мәдәниятләренә, гореф-гадәтләренә һәм теленә багышланган гала-концертта мәктәп укучылары, студентлар һәм эшләүче яшьләр катнашты. Финалда сигез кыз һәм биш егет чыгыш ясады. «Түбән Кама гүзәле» исемен Түбән Кама педагогика көллияте студенты Азалия Миндубаева яулады, ә «Түбән Кама батыры» исеменә 1 нче гимназия укучысы Дауд Хәбибуллин лаек булды.
(e-nkama.ru)

Әлки

Түбән Әлки авылында яңа клуб төзелә. Шактый эш башкарылган инде. «Яңа мәдәният йортын башта элеккеге урынында төзү уе бар иде. Әмма хәзер заманча таләпләр башка. Машиналар туктар урын, аңа килер асфальт юл кирәк. Менә шул бар инфраструктурасы белән аның әлеге урынга сыймавы ачыкланды. Шуңа да яңа төзелешкә башка җир бүленде. Ул элеккеге клубтан ерак түгел, шулай ук авыл үзәгендә», – ди авыл җирлеге башлыгы Фәрит Садриев. Яңа мәдәният йорты салу федераль программага кертелгән, аңа акча башкаладан бүлеп бирелә. Бүгенге таләпләр буенча заманча итеп салына. 100 урынга исәпләнгән, анда китапханә дә булачак.
(«Әлки хәбәрләре»)

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

Мәгълүмат эшкәртүче иң зур үзәкләрнең берсе. Казанда «Таттелеком» исәпләү үзәгенең яңа бинасын төзи башладылар. Үзәкнең нигез ташын салуда Татарстан Рәисе дә катнашты.
«Таттелеком»ның тарихы 135 ел элек башланды. Ә хәзерге компания буларак ул инде 25 ел эшли. Компанияне саклап кала алдык, ул республиканың цифрлаштыру юнәлешендә нигез булып тора», – диде Рөстәм Миңнеханов.
Республика Рәисе искәрткәнчә, Татарстан башкаласы өчен мондый зур үзәк бик кирәк.
Сүз уңаеннан, төзелеш эшләрен 2026 елга төгәлләргә исәп. Яңа бина 3 мең квадрат метр мәйданны биләячәк.

ИКЕ ЯКТА – БЕР НИЯТ

КЫТАЙ КОМПАНИЯЛӘРЕ ТАТАРСТАНДА ЭШЛӘРГӘ ТЕЛИ

Быел көз Казанда узган «РОСТКИ» Россия – Кытай форумыннан соң чит илдә республикага карата кызыксыну арткан. Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның Мәскәү өлкәсенә эш сәфәре барышында хәбәр иттеләр.

Рәис Мәскәү өлкәсендәге «Гринвуд» бизнес-паркында булды һәм Кытайның эшлекле даирәсе вәкилләре белән аралашты. Бизнес-парк 2010 елда Кытай капиталы катнашында төзелгән. Ул Россия белән Кытай арасында икътисадый һәм гуманитар хезмәттәшлек өчен мәйдан булып тора. Биредә кунакханә, конгресс-үзәк, сөйләшү бүлмәләре, банк бүлекчәләре дә бар. Бизнес-паркта 12 мең кеше эшли, 300дән артык компания тәкъдим ителгән. Алар арасында Кытайдан да 170 оешма бар. «Гринвуд» резидентларының Россия белән Кытай арасындагы товар әйләнешенә керткән гомуми өлеше 6 миллиард доллар тәшкил итә.

Бизнес-паркның мөмкинлекләре турында Рөстәм Миңнехановка «Гринвуд» АҖ президенты, Россиядә Кытай эшмәкәрләре берлеге рәисе Чжоу Люцин сөйләде. Моңа кадәр яклар «РОСТКИ» форумында очрашкан иде. Чжоу Люцин Казанда узган җыенның Россия – Кытай хезмәттәшлеге өчен әһәмиятен билгеләп үтте. «Форумнан соң күп кенә Кытай компанияләре Татарстан белән хезмәттәшлекне үстерүгә кызыксыну белдерде. Без эшлекле мөнәсәбәтләрне ныгытуда ярдәм итәргә әзер», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанда «Гринвуд»ның филиалын ачарга тәкъдим итте. Рәис Кытай эшмәкәрләрегә берлегенең абруен һәм аның ике ил арасындагы хезмәттәшлекне ныгытуга керткән өлешенә дә югары бәя бирде.

– Сезнең мәйданда республиканы тәкъдим итәргә, Кытай компанияләрен Татарстанның икътисадый һәм инвестицион мөмкинлекләре белән таныштырырга шат булачакбыз. Бергәләп Кытай эшмәкәрләренең безнең төбәккә бизнес-миссиясен оештыра алабыз. Кытай базарында республикада җитештерелүче кайсы төр продукциягә ихтыяҗ бар икәнен дә өйрәнергә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Кытайның эшлекле даирәсе вәкилләре белән аралашу барышында Рәис Кытайның безнең ил өчен стратегик хезмәттәш булуын билгеләп үтте.

– Кызганыч, пандемия безне берникадәр вакытка чикләде. Ләкин чикләр ачылуга, без үзара элемтәләрне кабат ныгыта башладык. Татарстан башкаласында узган «РОСТКИ» форумы төрле юнәлешләр буенча хезмәттәшлекне ныгытуда ике якның да кызыксынуын күрсәтте, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстанда уңышлы эшләүче Кытай компанияләре турында да әйтте ул. «Көнкүреш техникасын җитештерүдә әйдәп баручы «Хайер» заводы республикада бишенче заводын төзеде. Мондый мисаллар мөмкин кадәр күбрәк булырга тиеш дип саныйм», – диде Рәис. Аның сүзләренә караганда, сәүдә турындагы килешүләреннән бигрәк, урында җитештерүне җайга салуга игътибарны арттырырга кирәк.

Үзбәкстан белән дә элемтәләр ныгый. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында Үзбәкстанның Сурхандәрья өлкәсе хакиме Олугбәк Касыймов белән очрашты. Узган ел нәтиҗәләре буенча, Татарстан белән Үзбәкстан арасындагы товар әйләнеше 50 процентка артып, 290 миллион долларга җиткән. Очрашуда төбәкара дәрәҗәдәге хезмәттәшлекне ил башлыклары Владимир Путин һәм Шәүкәт Мирзиёев хуплавын да билгеләп үттеләр. «Алга таба товарлар һәм хезмәтләр белән тәэмин итү күләмен һәм төрләрен арттыру юнәлешендә эшләргә кирәк», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов. Исегезгә төшерәбез: Сурхандәрья өлкәсе – Үзбәкстанның иң көньяк төбәге. Икътисадының нигезен агросәнәгать тәшкил итә. Аерым алганда, биредә нечкә сүсле мамык сортлары үстерәләр.

ГАИЛӘДӘН БАШЛАНА

Дәүләт Советында традицион гаилә кыйммәтләрен саклау турында сөйләштеләр. Татарстан Парламенты Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин республикадагы иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре белән очрашты. Утырыш Татарстан Иҗтимагый палатасының «Хакимият белән әңгәмә» проекты кысасында узды.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, әлеге очрашуның Россия Федерациясендә Гаилә елы башлану алдыннан узуы аерым мәгънәгә ия. «Безнең күпмилләтле халкыбыз аңында, мәдәни кодыбызда үзара аңлашу, гаилә, өлкәннәргә, традицион гаилә кыйммәтләренә, туган телгә хөрмәт, тарихи хәтерне саклап калу, хезмәт сөючәнлек кебек сыйфатлар саклана», – диде парламент башлыгы.

Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, Татарстанда гаилә кыйммәтләренә аерым игътибар бирелә, моның өчен төрле чаралар уздырыла. Республикада күпбалалы гаиләләр саны 10 ел эчендә 2 мәртәбә артып, 42,4 меңгә җитте. Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, республикада балалы гаиләләргә ярдәм итү өчен күп эшләр башкарыла. Татарстанда 60тан артык социаль яклау чарасы гамәлгә ашырыла, алардан 1,2 миллионнан артык кеше файдалана. Бу эштә дәүләтнеке булмаган оешмалар да катнаша. Парламент башлыгы әйтүенчә, аларның өлешен арттырырга кирәк.

Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына республика тарафыннан аерым игътибар бирелә. Фәрит Мөхәммәтшин иҗтимагый оешмаларга бу эшкә ныклап кушылырга киңәш итте. Бергәләп хәл итәргә тиешле башка мәсьәләләр дә бар. Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, гаиләләр таркалу проблемасына игътибарны арттырырга кирәк. Россиядә өченче ел рәттән аерылышулар саны арта. Татарстанда вазгыять бераз яхшырак, әмма бездә дә борчылырга урын бар. Демографик вазгыять тә катлаулы. Фәрит

tatarstan.ru

Мөхәммәтшин фикеренчә, бу мәсьәләләрне икътисадый, сәяси чаралар белән хәл иткәндә рухи-әхлакый якны да онытырга ярамый. «Бәхетле һәм нык гаиләләр күбрәк булган саен, илебез дә көчлерәк булачак», – диде ул.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен **Гранковский** Андрей Владимирович, **Гранковская** Светлана Юрьевна Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ата-ана даны» ордены медале** белән бүләкләнделәр.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры **Җәббаров** Марат Азат улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе **Мерзакриев** Рөстәм Рәүф улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе **Хисаметдинов** Алмаз Гаптрәүф улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте «Татнефть-Добыча» структур подразделениесенең «Лениногорскнефть» нефть-газ чыгару идарәсе сусызландыру һәм тозсызландыру җиһазы операторы **Әхмәдуллин** Рафил Нуриэздан улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте «Татнефть-Добыча» структур подразделениесенең «Азнакаевскнефть» нефть-газ чыгару идарәсе җир асты катламнарындагы басымны карап тоту буенча операторы **Латыйпов** Фәнис Фәхразый улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ЮРИСТЛАР КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы юстиция министры
Рөстәм ЗАҺИДУЛЛИН
КОТЛАВЫ

Хөрмәтле юридик берләшмә вәкилләре! Сезне һөнәри бәйрәм – Юристлар көне белән котлыйм!

Татарстан көчле юридик мәктәбе белән данлы. Сыйфатлы хокук иҗат итү, норматив хокукый базаны камилләштерү, хокукны нәтиҗәле куллану практикасын формалаштыру, хокукларны һәм ирекләрне яклау буенча эшчәнлек Татарстан Республикасында хокук тәртибен һәм аның үсешен тәэмин итә.

Юристларның хезмәте социаль җаваплылык, җәмгыятьтә хокукый мәдәниятне арттыру, гражданнарга квалификацияле, шул исәптән бушлай юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле.

Бүген махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына хокукый ярдәм күрсәтүгә аерым игътибар бирелә. Юридик берләшмәгә хас актив гражданлык позициясе, үз эшен белеп башкару һәм намуслылык һәрвакыт хокукларны һәм ирекләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итүнең нигезе булып хезмәт итәчәк, дип ышанам.

Сезгә нык сәламәтлек, эш дәрте, иминлек, бәхет һәм һөнәри эшчәнлегегездә югары нәтиҗәләргә ирешүегезне телим!

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Хаталану

Бу уйларның дөреслектән ерак икәнен дә, сезнең фикерләр белән туры килмәячәген дә аңлап торам инде мин. Тик уй бит ул, кайчагында чылбыр белән кулыңа урап, урамга алып чыккан бозау зурлык эт шикелле – күзе берәр нәрсәгә төшә дә сине дә шунда сөйрәп алып китә. Зур омтылыш белән эшләнгән гамәл күп вакытта дөреслек тә булып тоела әле. «Ул хаклыдыр, хаклы булмаса, шулкадәр ашкынмас иде», – дисең. Бу уйлар да шул чамарак...

Бер мәлне һич көтмәгән-уйламаганда колорадо коңгызы килеп чыкты. Мин бик кечкенә идем әле. Кызыл-сары төстә, кара төрткеләре дә бар икән дип сөйләнгәч, без, дәү әни белән бакчага чыгып, безнең якта «тәти кош» дип атала торган коңгыз җыеп кердек. Шуннан үзен танытты инде Америка коңгызы, эстрада йолдызы кебек булды. Ә ул чакта ачлык елларны бәрәңгегә тотынып исән калган халык бик пошаманга төште. «Йодрык кадәрле йомры бәрәңге», – дип җырлыйлар иде бит. Колорадо коңгызы хакимлек урнаштырганнан соң, Уфадан авылга кайткан бер апаның сүзләре истә калган:

– Берәр чиләк кенә алып китим әле, шәһәрдә кыйбат. Быел бәясе ике тапкыр артты.

Күңелеңә кереп, тынгылык бирми йөри торган шигырь дә, баш миен кытыклатырлык канатлы сүз дә түгел инде бу. Чираттагы шәһәр кешесенең нәүбәттәге зарлануы гына. Тик ул онытылмады. Чөнки шуны хәтерләтә торган хәлләр әледән-әле килеп чыгып торды.

Бер мәлне «кош гриппы» килеп чыкты. Аның белән берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр таралды. Фәлән җирдә фәләнешәр мең казны юк иткәннәр икән... Тавык фермасын яндырганнар икән... Карга-чыпчыкка кадәр кыралар икән... Авыл халкы шомланды инде. «Фәлән җир» дигәннәре бездән еракта булса да, куркыта бит. Авыл халкы да кош-кортны абзардан чыгармады, чыпчык-карганы ихатага якын китерергә тырышмады. Тик күпмедер вакыт узуга ук, шәһәрдән кайткан кешеләрнең зарлы авазлары ишетелде:

– Йомырка кыйбатланган!

– Кош итенә хак арткан!

Беркадәр вакыт узгач, шундыйрак хәбәр таралды:

– Безнең силос базыннан да зуррак чокырлар казып, абрикос, слива, виноград ише җимешләрне шунда салып таптатканнар икән.

Гади халык моның кайда икәнен дә, нилектән шулай булуын да әйтә алмады. Үзе дә аңламады. Колорадо коңгызы яки кош зәхмәте төшә торган нәрсәләр түгел бит инде. Артык кайгыручы да булмады бугай. «Алай икән», – дип кенә куйдык. Күпләребезнең андый җимешләрне ашаганы гына түгел, күргәне дә юк һәм аның ни өчен кирәк икәнен дә аңламый идек. «Бик әйбәт, бәрәңге үстерсеннәр. Бәрәңге ул – настаяшный җимеш», – дип куйды күрше Мөхәммәтҗан бабай да.

Күп тә үтмәде, кибетләргә кайта торган җимеш суларына, повидло, варенье, кәнфит кебек нәрсәләргә хак артты. Шәраб та кыйбатланган. Аны да шундый җимешләрдән ясыйлар икән.

Барсын да санасаң, озакка китә. Тик бар нәрсәнең дә шул даимилек белән кабатлануын аңлагач, ниндидер закончалык кебек нәрсә килеп чыга. Афәт килгән икән... Димәк, кыйбатланачак...

Соңгы елларда адәм башына да бер-бер артлы афәт килеп тора. Я ул бар дөньяны яулап алган зәхмәт-чир рәвешендә, я гади кешеләрнең улларын чүпли торган ут чәчүче аждаһа кыяфәтендә була...

Күп нәрсәләрдә хаталанамдыр инде мин. Бернинди дә закончалык түгелдер, теге күзәтүләрнең чынбарлыкка бөтенләй дә катнашы юктыр. Тик ул уйлар сөйрәп алып китә... Һәм өмет уята... Шушы хәлләрдән соң кеше гомере дә югарырак бәяләнә башлар сыман тоела.

Әйтеп кенә бактым

Сәер кавышу

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Ир белән хатынның яшәгән саен бер-беренә якыная баруын ничек аңлатырга? Бер уйлаганда, моның сере бик гади: кеше олыгайган саен үзенә таяныч, терәк кирәген күбрәк аңлый башлый. Мәрхүм Туфан ага Миңнуллинның: «Хатын, картайгач, сине диваннан тартып торгызу өчен генә булса да кирәк», – диюен шаяртуга да борып булыр иде. Тик асылда бу сүзләрдә нәкъ менә таянышып яшәүгә бер ишарә бит.

Гомумән алганда да, бәндә тумыштан ук үзенә таяныч эзләп яши. Ирләргә – булдыклы хуҗабикә, хатын-кызга җил-яңгырдан ышыклаучы ир кирәк. Тик менә кайчак үзеңә лаеклыны табу гына бик җиңел түгел. Шуңа күрә, дус-ишләр белән очрашканда, без танышу-кавышу мизгелләрен сагынып искә алырга яратабыздыр да.

Күптән түгел мәзәккә тартым бер вакыйга турында сөйләделәр. Бер оешмада эшләгән егет белән кызның кавышуы никтер көтелмәгән була. Кияү дигәнебез – инде кырыкка якынлашып килүче өйләнмәгән карт егет, шул оешмадагы бер бүлек җитәкчесе. Килен буласы кеше – утызны куып баручы кыз, карт кызлар рәтенә аяк басарга да күп калмаган. Шуңа күрә соңгы вакытларда еш кына тынычлыгы югала кызның, төшенкелеккә бирелә башлый. Төскә-биткә чибәр, бик булдыклы, эшендә дә бик яраталар, җитәкче егет тә аның кадерен белә, җае чыккан саен булышырга тырыша. Хәтта күпмедер дәрәҗәдә сердәшләргә дә әйләнә болар.

Бер көнне кыз шефына: «Фәлән Фәләнеч, кияүгә чыгарга да вакыт җитте, танышларыгыз арасында берәр юньле кеше юкмы?» – ди.

– Соң, синең арттан егетләр көтүләре белән йөри түгелме соң?

– Йөрүен йөри дә, ник шуларның берсе, миңа кияүгә чык, дип әйтсен! Җыен бозау... – ди кыз.

Юньле җитәкче үзенең кул астындагыларга барлык шартларны тудырырга, һәр гозеренә колак салырга тиеш бит инде. Егет әнә шундый юньле җитәкчеләрнең берсе була һәм кызга тормыш итәрлек бер яхшы егет табарга вәгъдә бирә. Бирүен бирә, кызны яшьләр күп җыела торган төрле тамашаларга, кичәләргә, театр-концертларга да алып йөри башлый. Әмма нәтиҗә нуль. Кыз инде җитәкчегә үпкәли дә башлагандай итә, үзенең булдыксызлыгыннан җитәкче дә ояла. Һәм беркөнне, аптыраганнан дигәндәй: «Миңа гына чыкмыйсыңмы соң?» – ди. Ә кыз, ике дә уйламыйча: «Алсаң, чыгам», – ди. Менә дигән итеп туй үткәрәләр болар һәм, җырдагыча әйтсәк, «пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп» яши башлыйлар.

Бу сәер хәлне уйлап чыгармадым. Егетнең әтисе белән күптән таныш мин. Якыннан аралашып яшәмәгәч, улының гаилә кору серләре турында гына ишеткән юк иде. Ә менә бу заманда кияүгә чыга алмый интеккән кызларның шактый икәне, ә көчле затлар арасында гаилә тотудан куркучыларның ишәя барулары турында ишеткәнем бар. Демографик вазгыятьне яхшырту турында сүзләрнең һаман куера баруы да тикмәгә түгел, димәк.

Тагын ни әйтим инде... Иң әйбәте яшь чак – юләр чакта гаилә кору түгел микән?! Икең бергә әкренләп кенә акылга киләсең, бөтен сынауларны бергә узган парлар, гадәттә, бәхетле яши. Ныклап аякка баскан бай ир-атлар һәркемгә җитмәс бит, диюем.

ЙОМЫРКА ТАБЫШМАГЫ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Ун ел элек "Йомырка сикереше" дигән язма эшләгән идем. Интернет аны саклаган икән. Әйе, әйе, хәтерлим: ул чакта да тавык йомыркасына бәя күтәрелү уңаеннан зур шау-шу купкан иде. Рәсми хакимиятләр йомыркага бәяне буып куярга омтылдылар, аның сәбәпләрен ачларга һәм аңлатырга тырыштылар. Файдасы гына аз булды.

Мин язганмын: «Ни генә дип аңлатсалар да, йомырка түбән тәгәрәргә җыенмый». Гадәттәгечә, рәсми пропагандадан читкәрәк китеп аңлатканмын «йомырка бию»нең сәбәпләрен. «Бу халыкның фәкыйрьләнүе һәм билләрне кысып бууы турында сөйли. Икенче төрле моны кризис дип атыйлар. Димәк, йомырка безгә 2014 ел турында җитди хәбәр сала: эшсезлек артачак, хезмәт хакларын түләүне тоткарлаячаклар һәм киметәчәкләр, банкларның бөлүе дәвам итәчәк, шуңа күрә икътисадый проблемаларыгызны хәл итәргә тырышыгыз, сәламәтлегегезне саклагыз, кредитлар алмагыз, акчаны банкка салмагыз, кыйммәтле, әмма әһәмиятсез әйберләргә кызыкмагыз...» – диебрәк фәлсәфә куертканмын. Ул фаразларны 2014 елның декабре 146 процентка тормышка ашырды: халыкны юләрләндерә торган валюта паникасы булып узды, кешеләр бер дә кирәкмәгәнгә кибетләрдән икешәр-өчәр телевизор һәм көнкүреш техникасы ташыды (соңыннан аларның бәясен түбән куеп та сатып булмады), процентлар күккә ашты. Үзәк банк төп ставканы 17 процентка җиткерде. Кредит алып, товар җитештерүчеләр зар елады. Статистика әйтә: без хәзер уннеңче елдагыга караганда матди яктан ике тапкыр диярлек начаррак яшибез. Әйтик, 2015 елның кырыс шартларында бу юлларның авторы, кредит алмыйча, өй салды, ярты өй салырлык акчасын чит илгә сәяхәткә тотты. Боларның берсе турында да хәзер хыяллана да алмый. Өйгә сыйфатлы бер ишек куйдыру йөз мең тирәсенә төшә, юк кына бер материал алыйм дисәң, айлык хезмәт хакың пүчтәк булып чыга. Автомобильләрнең янына якын килерлек түгел. Искесен карап кына тотмасаң, җәяүлегә каласың. Үзәк банк төп ставканы 16га җиткерергә җыена. Доллар тагын яхшы ук сикерде. Дөрес, соңгы көннәрдә сумны бераз ныгыттылар, әмма Песков әйтә: «Хөкүмәтнең икътисад блогы «сумнар әйләнеше» турында мәгълүматны тикшерә», – ди. Баксаң, читкә товар сатучылар, валюта керемен мәҗбүри рәвештә сату турында карар гамәлгә кергәч, чит илдә сумнарга валюта сатып алып, Россия базарында сатарга мәҗбүр икән. Аңлашыла торгандыр инде: бу юл белән ерак китеп булмый. Дус илләрдә сумнарны валютага алыштыру проблема түгел, әмма акчаны Россиягә кертү – чып-чын баш авыртуы. Комиссиясенә түзү кыен. Шулай булгач, 2024 ел безгә яңа валюта сюрпризлары әзерләми дип кем әйтә ала?

Иң кызыгы: тавык йомыркасы тагын 2013 ел ахырындагы биеклеккә менде, ул безнең яраклы товар, бәясе ел эчендә 21 проценттан да артыкрак сикерде, ди. Амур өлкәсендә аның дистәсе 150 сумга җиткәч, монополиягә каршы федераль хезмәт аякланды: йомырка җитештерүчеләрне тикшерә башлады.

Бераз гына Татарстан статистикасы белән мавыгып алыйк. Иң соңгы бәяләр мониторингы 22 ноябрьгә карый. Ул көндә бездә йомырканың дистәсе 99 сум 48 тиен торган. Бу алдагы атнадан 3,71 процентка кыйммәтрәк. Йомырка инфляциясен еллыкка күчерсәк, күпме була? Йомырка шул темплар белән сикерүен дәвам итсә, бу инде инфляция дип түгел, гиперинфляция дип аталыр иде. Ләкин тагын бер хикмәт бар. Без атаган сан, гафу итегез, күкәйнең уртача бәясе. 22 ноябрьгә йомырка бәясе Спас районында – 123 сум 87 тиен, Яшел Үзәндә – 118 сум, Саба районында 115 сум йөргән. Ел башында Татарстанда уртача бәя – 77 сум 50 тиен.

Йомырка бәясенең гел шулай яңа биеклекләр яуларга яратуының серен аңларга теләп, монополиягә каршы хезмәт чиновниклары махсус тикшерү үткәргән. Нәтиҗәсе мондый: йомырка бәясендә кошчылык фабрикаларын тотуга киткән чыгымнар өлеше (моңа продукцияне кибетләргә кадәр илтеп җиткерү чыгымнары да керә) – 6 процент, хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә киткән акча – 7 процент, энергия чыганакларына түләү (иң беренче чиратта газ һәм электр бәясе) – 32 процент, сәүдә челтәрләре өстәгән бәя – 30 процент, кошлар өчен азык бәясе – 25 процент. Саннарга карагач, бездә йомырканы сәүдәгәрләр сала икән дигән уй килмиме башыгызга? Йомырканы чын җитештерүчеләр аның акчасыннан бер дә файда күрми. Менә әйтеп карагыз әле: кошчылык фабрикасын тоту кыенракмы, кибетләр челтәренме? Бер нәрсәне исегездә тотыгыз: сәүдә челтәрләре бер йомырка гына сатмый, башка меңләгән товарга да бәяне яхшы ук өстиләр. Саннар хәзерге икътисадның бар гариплеген күрсәтә. Заводларда һәм фабрикаларда, авыл фермаларында һәм кырларында һаман да нәрсәләрдер җитештерелә алуы таң калдыра. Ләкин антимонополь хезмәт саннарны өстән-өстән генә алган, барлык чыгымнарны да күрсәтеп бетермәгән. Йомырка бәясендә банкирлар өлеше кайда? Табышыннан банкка кредит түләмәгән бер генә җитештерүчене атап карагыз миңа. Процентлар үскәч, бурычларны товарга бәя күтәрмичә ничек түлисең? Безнең икътисадның бөтен каймагын нәкъ менә шул банкирлар файдалана да инде. Төптән уйлап карасаң, энергия чыганакларына бәядә дә, кош азыгы бәясендә дә, хәтта кошчылык фабрикасы стенасының үзкыйммәтендә дә рибачылар өлеше шактый гына, чөнки нәрсәгә генә килеп тотынма, аннан процентлар исе килә. Бөтен финанс системасы, бөтен бюджет асылда шуларга хезмәт күрсәтә.

Икенче урында, мөгаен, сәүдәгәрләр торадыр. Сезне кибетләрнең күплеге алдамасын. Урам саен, чат саен берничә кибет булуга карамастан, алар нигездә берничә монополист кулында. Шуңа күрә алар, бер дә курыкмыйча, «торговая наценка» дигән әйберне бик мул куялар. Антимонополь хезмәт боларны ни эшләтә ала? Берни дә эшләтеп булмый. Шуңа күрә ихтыяҗ бар икән, товарга бәя котылгысыз үсәчәк. Йомыркага ихтыяҗ һәрвакыт була, чөнки ул – «Гиффен товарлары» исемлегендә. Гиффен товарына бәя күтәрелә икән, халык аны тагын да күбрәк сатып ала башлый. Моннан ун ел элек мин шул хакта язганмын.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Зөһрә
САДЫЙКОВА

АФӘТ

ТАТАРСТАНДА 30 ЕЛ КҮРЕЛМӘГӘН КУРКЫНЫЧ АВЫРУ БАШ КАЛКЫТТЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

5,5 мең башка якын терлек юк ителәчәк. Әтнә районының «Тукай» хуҗалыгында бруцеллез авыруы килеп чыгу нәтиҗәсе бу. Терлекләр өчен дә, кешеләр өчен дә куркыныч булган авыру Татарстанда 30 ел күрелмәгән иде. Быел исә инде икенче очрак. Күптәннән булып, инде онытыла төшкән авырулар ни сәбәпле баш калкыта? Тагын нинди куркыныч авырулардан сакланырга кирәк? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауларга җавап эзләде.

Сөт түгелә, маллар юк ителә

«Тукай» хуҗалыгы – терлекчелектә алдынгылыкны саклап килгән Әтнә районында иң эре һәм моңа кадәр иң уңышлы эшләгән оешмаларның берсе. Комплекста 5,5 мең баш терлек бар, шуларның 2,177 меңе – савым сыеры. Гади генә сыерлар түгел. Күп сөт бирүче токымлы маллар. Хуҗалык көн саен 60 тонна сөт савып алды. Бу – районда җитештерелә торган барлык чималның 17 проценты һәм республикада иң яхшы күрсәткечләрнең берсе. Рәсми чыганакларда күрсәтелгәнчә, узган ел хуҗалык 18,4 млн кг сөт савып алган, игенчелек һәм терлекчелектән 752,9 млн сум керем керткән, шуның 290,3 миллионы – чиста табыш.

Бу хәл – билгеле, район өчен дә, республика өчен дә зур югалту.

– Агрофирма – районда иң күп сөт җитештерүче. Мондый хәл килеп чыгу бик кызганыч, сүз дә юк. Хәзер карантин игълан ителде. Инде авыруны башка хуҗалыкларга таратмас өчен, барысын да эшлибез. Югары технологияле фермаларда барысы да автоматлаштырылган иде. Кызганыч, бу гына коткарып кала алмады, – диде районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ленар Сәмигуллин.

Бу хәлләр килеп чыкканчы, хуҗалык сыерларының бозау салу очраклары артуга игътибар итә һәм маллардан кан анализлары алалар. Кызганыч, анализлар терлекләрдә бруцеллез авыруы булуын ачыклый. Шул ук көнне, ягъни 23 ноябрьдә, фермадан сөт чыгару туктатыла һәм карантин кертелә. Бу территориядә терлекләрне дәваларга, кертергә һәм алып чыгарга (бары тик эшкәртер өчен булса гына ярый), сөтне алып чыгарга, кулланырга ярамый, терлек азыгын, җиһазлар алып чыгу тыела.

Әлеге вакытта хуҗалыкта мөгезле эре терлекләрнең барысыннан да кан анализы алалар. Авыру табылганнары шушы бер-ике көн эчендә Дагыстанга озатылачак. Анда хезмәткәрләре бруцеллезга каршы прививка ясаткан махсус оешма бар икән. Соңгы мәгълүматлар буенча, андый сыерлар саны 700гә якын иде. Ләкин бу әле ахыргы саннар түгел. Калганнары районлагы чалу цехында эшкәртеләчәк.

– Хуҗалыкның авыру табылмаган малларының ите сатуга чыкмаячак, ә колбаса цехына озатылачак. Югары температурада бруцелла бактерияләре тулысынча юкка чыга. Сөтләрен исә, зарарсызландырып, түктеләр, – дип аңлатты Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин.

Сәбәпләре

Мондый хәл ничек һәм каян килеп чыгарга мөмкин? Әлегә сәбәпләрен кистереп әйтергә ашыкмыйлар. Төрле фаразлар бар: тычканнардан алып диверсиягә кадәр.

– Хуҗалык читтән терлек алып кайтмаган. Шуңа күрә бу очракта кеше факторы булырга мөмкин. Авыру чыганагы терлек белән дә, техника белән дә, кеше аша да эләгә ала. Монда бик күп сәбәпләр бар, – диде җитәкче.

Әгәр чыганак кешеләр, техника аша башка җирләрдән килергә мөмкин икән, авыруның башка хуҗалыкларда да булуы ихтимал бит? Бу сорауга Габделхак Мотыйгуллин болай дип җавап бирде:

– Мондый хәл булмас, дип әйтә алмыйбыз. Шуңа күрә барлык районнар да уяу булырга тиеш. Без дезинфекция узмаган техниканы территориягә кертергә ярамавын гел әйтеп киләбез. Ферма эшчеләре санитария таләпләрен узып керергә һәм чыгарга, махсус киемнәрдән эшләргә, аннан соң аны юарга һәм дезинфекцияләргә тиеш. Ләкин мөгезле эре терлек комплексларында бу таләпләр үтәлеп бетми. Хәзер моңа тагын да зуррак игътибар биреләчәк, – диде Габделхак Мотыйгуллин.

Рәсми чыганаклар терлек, кеше, техника һәм башка сәбәпләрне атасалар да, рәсми булмаганнары авыруның шушы ук территориядә урнашкан мал чалу цехыннан да килеп чыгу ихтималын инкарь итми.

Шәхси хуҗалыклар

Районлагы башка хуҗалыкларны да тикшергәннәр, бруцеллез табылмаган. «Тукай» хуҗалыгында эшләр төгәлләнгәч, шәхси хуҗалыклардагы терлекләрне дә тикшерәчәкләр. Имин булмаган торак пунктларга дүрт авыл керә.

– Халыкның кәефе начар түгел, аларга бернинди дә зыян юк, зарланучылар да күренми. Сөтләрен җыялар. Барысын да аңлаттык, каударлану, паникага бирелү дигән нәрсә юк, – дип сүзен кыска тотты Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы Сергей Порфирьев.

Шулай да кешеләр арасында шикләнүчеләр дә бар.

– Бу хәлләр барыбызны да пошаманга салды, әлбәттә, – диде Олы Әтнәдә яшәүче исемен күрсәтмәүне сораган ханым. – Зур, яхшы хуҗалык иде. Малкайлар бик кызганыч. Авылда да күпләп терлек асраучылар шактый. Безнең үзебезнең дә ике сыерыбыз һәм үгезебез бар. Сөтне җыялар, тик без бу көннәрдә бирми тордык әле. Саклану чараларын беребез дә тиешенчә үтәми инде. Бу хәл теләсә кайсыбызда була ала. Күрәчәк булмасын.

Кешеләргә дә куркыныч

Бруцеллез – терлекләр һәм кешеләр өчен куркыныч булган йогышлы авыру. Маллар арасында аеруча сарыклар, кәҗәләр, мөгезле эре терлек һәм дуңгызлар авыруга нәзберек. Белгечләр әйтүенчә, бруцелла бактериясе азык, су һәм һава аша күчәргә сәләтле. Күп очракта авыруның билгеләре юк. Ләкин хуҗалыкта сыерлар бер-бер артлы бозау сала башлый икән, кичекмәстән анализ тапшырырга кирәк.

Авыру кешеләргә йогуы белән дә куркыныч. Бруцеллез терлек янында булганда яки аның итен – пешеп бетмәгән, сөтен кайнамаган килеш кулланган очракта йогарга мөмкин. Кешеләрдә авыруның иң төп билгеләре – буыннар авырту, җенес органнары ялкынсыну.

Без сөйләшкән көнне Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе белгечләре «Тукай» хуҗалыгының эшчеләреннән анализлар ала иде. Нәтиҗәләре берничә көн эчендә билгеле булачагын әйттеләр.

Могҗиза көтмик

Быел бу куркыныч авыруның республикада икенче очрагы. Сентябрьдә Яңа Чишмә фермеры Николай Скоков хуҗалыгында бруцеллез чыгып, 700 баштан артык терлеге юк ителгән иде. Аңа кадәр 30 ел булмаган авыру ни өчен янәдән баш калкытты?

– Россия буенча бруцеллез авыруы киң таралган. Әлеге вакытта илнең 26 төбәгендә бруцеллезга каршы вакцина ясыйлар. 43 төбәк имин түгел дип санала. Моңа кадәр сакланып килдек, менә быел гына проблемалар булды, – диде Габделхак Мотыйгуллин. – Бруцеллез, тилчә кебек авырулар җиңел машиналарның багажнигында да керергә мөмкин. Аларны тикшереп бетерү мөмкин түгел. Әле быел гына күрше төбәкләрдә тилчәнең берничә очрагы булды. Алар белән чиктәш районнарга постлар куеп сакланырга туры килде. Шуңа күрә без куйган таләпләрне үтәү өчен вакыт килеп җитте, могҗиза көтүдән мәгънә юк.

Җитәкче әйтүенчә, бруцеллез гына түгел, кош гриппы, дуңгызларда Африка чумасы да беркая китмәде. Шулай ук бик куркыныч булган тилчә, нодуляр дерматит, Себер түләмәсе авырулары да терлекләргә бик зур зыян салырга сәләтле.

Сорау – җавап

• Авыру маллардан савып түгелгән сөт башкалар өчен куркыныч тудырмыймы?
– Сөт дезинфекция ясалганнан соң гына түгелә, шуңа күрә башкалар өчен аның куркынычы юк.

• Чикләү чаралары барлык Әтнә районына кертелдеме?
– Әлегә тыюлар башка хуҗалыкларга кагылмый. Дүрт авыл имин булмаган торак пунктлар булып санала, аларның продукциясен чыгару тыелмый.

• Авыру булмаган сыерларның сөтләре сатыламы?
– Хуҗалыкта бруцеллез табылган очракта, аннан бер продукция дә чыгарылырга тиеш түгел.

• Ничек сакланырга?
– Читтән терлек сатып алырга теләгән очракта, башта ветеринария берләшмәләре белгечләре белән киңәшү кирәк. Малларны машина белән читтән китереп сатучылардан алмау хәерле. Ит һәм сөт ризыкларын 100 градустан да ким булмаган температурада пешереп яки кайнатып ашарга кирәк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КЫЙММӘТЛЕ ЯҢА ЕЛ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Алтынга тиң мандарин

Алдагы ел белән чагыштырганда, быел Яңа ел табыны якынча 10 процентка кыйммәтләнгән. «Руспродсоюз» белгечләре исәпләвенчә, өйдә дүрт кешелек гаиләгә бәйрәм табыны әзерләү өчен уртача 5,5 мең сум акча кирәк булачак. Былтыр, мәсәлән, Яңа ел өстәленә 5 мең сум җиткән. Илдә яшәүчеләр табынга ешрак нәрсә куйганын да әйткәннәр. Бәйрәмне күпчелек «кышкы», «тун астындагы балык» салатлары, иттән икенче аш, кызыл уылдык бутербродлы, җиләк-җимеш һәм сыр-колбаса ашап каршы ала икән.

«Бәйрәм табыны ник кыйммәтләнгән?» дигән сорауга да җавап бар. Килешәсездер: Яңа елны мандариннан башка күз алдына китереп булмый. Ә ул быел икеләтә диярлек арткан. Росстат мәгълүматларына караганда, агымдагы елның октябрендә, узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, ул 83 процентка кыйммәтләнгән. Бер кило мандаринның бәясе уртача 202 сумга җиткән. Кайбер кибетләрдә аны 300–350 сумга да очратырга мөмкин. Дөрес, алга таба мандарин бәясе төшәчәк, дип тә тынычландырганнар. Импортны җайга салганнар, имеш. Тик бер арткан бәянең кире төшүе генә шикле. Бигрәк тә Яңа ел алдыннан. Быел тавык ите дә шактый кыйммәтле ризыкка әйләнде. Ел башыннан бирле аның бәясе 27 процентка арткан. Ите генә түгел, йомыркасы да кесәгә суга.

– Бу арада бәйрәм арты бәйрәм, әзерләнеп кенә өлгер, – ди Минзәлә районының Куян авылында яшәүче фельдшер Вәзирә Гыйльмуллина. – Бу атнада үгез суябыз, авыл җирендә ул да зур бәйрәм кебек. Туганнарыбыз да кайтачак. 8 декабрьдә – туган көнем. Анда да бөтен туган-тумача бер табын янына җыелышачакбыз. Яңа елга кадәр бәйрәмнәр күп әле *(көлә.)* Аллага шөкер, бүген тормышыбыз бар яктан да җитеш. Тарсынып торган юк, ашыйсы килгән әйберне алып ашыйбыз. Авыл җирендә ул яктан җиңелрәк: җиләк-җимеш, яшелчә бакчада үсә. Яңа ел бәйрәме ит бәлеше, пешкән каздан башка да узмый. Барысы да үзебезнеке. Бернича төрле салат ясыйбыз. Бәйрәмгә туганнар килә йә үзебез барабыз. Каникулга балалар да кайта. Әнә шулай рәхәтләнеп аралашып яшибез. Сөйләшә-сөйләшә төнге сәгать ике тулганны сизмичә дә каласың. Яңа ел бәйрәме дигәч тә, табын янында ашап-эчеп утыру гына түгел бит ул, без аны үзара очрашу, аралашу мөмкинлеге өчен яратабыз. Ә бу акчага караганда да кыйммәтрәк.

Соңга калмагыз!

Яңа ел бүләксез дә булмый. Бу – бәйрәмнең иң чыгымлы өлеше дә әле. Бөтенроссия халык фикерен өйрәнү үзәге үткәргән сораштыруда катнашучыларның 60 процентка якыны шулай дигән. Илдә яшәүче ун кешенең сигезе Яңа елга якыннарына, дусларына, эштәге хезмәттәшләренә бүләк бирергә җыена. Моның өчен күпме акча тотачаклары да билгеле. Респондентларның 30 проценты бүләккә 5–10 мең сум акча туздырырга ниятли. Тагын шул кадәре бәйрәм кәефе өчен 15–25 мең сум акча кызганмаячак. Илдә яшәүче һәр сигезенче кеше исә Яңа ел төнендә кадерле кешеләрен сөендерү өчен 50 мең сум тотарга әзер. Менә шундый юмартлык. Бүләкләрне күбрәк балаларга һәм хатыннарга бирәчәкләр. Беренче бишлеккә әтиәниләр, ирләр һәм дуслар да эләккән.

– Бүләк сатып алуны иң соңгы көнгә калдырырга ярамый, чөнки Яңа ел якынлашкан саен акчаның исәбе югала, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Гадәттә, без зур сәүдә үзәкләрендә акча күп тотабыз. Андагы матурлыктан күзләр камаша да, кирәкле товар белән бергәттән, кирәкмәгәннәре дә кәрзингә эләгә. 31 декабрь алдыннан кибетләрнең бәя күтәрүе дә – гадәти хәл. Шуңа күрә бүләкләрне мөмкин кадәр иртәрәк әзерләп куярга кирәк. Товарны рассрочкага сатып алырга да ашыкмагыз. Чөнки бәйрәм мәшәкатьләре белән кредит килешүендә өстәмә хезмәтләр тәкъдим итүләрен сизмичә калуыгыз бар. Кесәдә булган акчаны туздырып бетермәгез, 31 декабрьдән соң да тормыш дәвам итә. Яңа елга бурычларсыз керәм дип, бөтен маяны әҗәтләрне каплауга юнәлтү дә үз-үзен акламый. Ни генә булмасын, өйдә «финанс мендәре» булырга тиеш. Бездә, мәсәлән, Яңа ел бүләкләрен гаиләбез белән бергәләп төрү гадәте бар. Шул рәвешле вакытны да бергә үткәрәбез, акча да янга кала.

Яңа елга күпчелек ашый-эчә торган бүләк бирергә җыена. Икенче урында – җылы кием-салым һәм йорт кирәк-яраклары. Бизәнү, косметика әйберләре исә – өченче. Аякны чын мәгънәсендә юрганга карап сузасы. Быел урын-җир кирәк-яракларына бәя 20 процентка кадәр арткан әнә.

– Сыйфатлы мамык, сатин тукыма Үзбәкстан һәм Төркиядән кайта. Товарны читтән кайтарту инфляция һәм доллар курсына бәйле булгач, бәясе дә кыйммәтләнә, – ди декрет ялында мендәр, юрган тышлары тегү белән шөгыльләнүче Алия Яруллина. – Былтыр сыйфатлы мамык тукымадан тегелгән ике кешелек урын-җир кирәк-яраклары 2,8 мең сумнан башланса, бүген 3,5 мең сум тора. Бәясеннән тормыйлар, алалар.

Җырчы Алсу Фазлыева Яңа елда кемнәргә бүләк бирәсен уйлап та куйган инде.

– Бәйрәмне кайда каршы алырбыз, анысы әлегә билгесез, шунысы хак: әни белән булабыз. Малайлар зур инде, Кыш бабайга ышанмыйлар. Ә кызыбыз Зифа кечерәк әле. Аңа Кыш бабай чакырырга да куркып торам. Бүләкләргә килгәндә, аларны кемнәргә бирәчәгемне төгәен беләм. Исемлекне барлап куйдым. Ел буе янәшәмдә булган кешеләргә, үземә ярдәм итүчеләргә игътибар күрсәтәсем килә. Безнең гаилә традициясе дә бар – Яңа ел алдыннан фотосессиягә барабыз. Балаларның үскәнен шул фотолардан күрәбез. Декабрь әнә шундый күңелле мәшәкатьләр белән үтә дә китә, – ди җырчы.

47 меңлек Бабакай

Стилист Диана Борһанова әйтүенчә, яшел аждаһа зәвык ярата.

– Гүзәл затларга Яңа ел төнендә яшел, кызыл, алтын, шәмәхә төстәге күлмәк кияргә киңәш ителә. Атлас, ефәк тукымага өстенлек бирсәгез яхшырак. Ир-атларга исә пиджак-чалбар киясе. Карарак төстәге күлмәккә өстенлек бирегез. Хәзер кибетләрдә ташламалар чоры, шуңа күрә бәйрәмгә артык зур чыгымнарсыз да кием сатып алырга мөмкин, – ди белгеч.

Бәйрәм кәефе өчен чыршы һәм Кыш бабай да кирәк, әлбәттә. Бүген күпчелек өйләрдә ясалма чыршы тора, шуңа күрә акча да тотасы юк. Кыш бабайны чакыруга килгәндә, Казанда быел бәяләр 2–3 мең сумнан башлана.

– Яңа елга заказлар килә башлады инде, – ди җиде елдан бирле Кыш бабай һәм Кар кызы булып эшләүче Алия һәм Олег Тихоновлар. – Әлегә күбрәк корпоративларга һәм спорт мәктәпләренә чакыралар. Декабрь урталарыннан «эш»кә чыгабыз. Безнең хезмәтнең бәясе, атнаның кайсы көненә һәм вакытына карап, 2–4 мең сум тора. Бәйрәм оешТыру белән шөгыльләнүче үзәкләр белән чагыштырганда, бу бик арзан. Аларда бәяләр ким дигәндә 10–12 мең сум. Былтыр 31 декабрьдә бер минуты 8 мең сум булган Кыш бабайлар турында да ишеткән бар. Без акча өчен генә йөрмибез. Кыш бабай костюмы гына да 47 мең сум тора. Яңа ел кәефе бүләк итү ошый. Балаларны котларга эштән соң йөрибез. Ял көннәрендә 10–15 баланы котлаган чаклар да була.

Былтыр илдә яшәүчеләр Яңа елны каршы алырга уртача 38,5 мең сум акча тоткан. Быел чыгымнар ким дигәндә 5–8 меңгә артыграк булачак, дип фаразлаганнар. Хуш киләсен, Яңа ел!

Татарстанның төп бәйрәм мәйданын 15 миллион сумга бизәячәкләр.

БӘЙРӘМ АРТЫК ЧЫГЫМЛЫ БУЛМАСЫН ӨЧЕН НИШЛӘРГӘ?

Финанс киңәшчесе Айдар ГӘРӘЕВтән 5 киңәш

1. Бәйрәм бюджетын алдан исәпләп куегыз.
2. Якыннарыгыз һәм туганнарыгызга бүләкләр сатып алуны декабрь азагына калдырмагыз.
3. Яңа ел табынына бозылмый торган азык-төлекне алдан хәстәрли башлагыз.
4. Бәйрәмгә нинди күлмәк киясен уйлагыз.
5. Яңа ел каникулына «сәяхәт маршруты» төзегез.

Сораштыру

ЯҢА ЕЛГА БҮЛӘКЛӘР ӘЗЕРЛИ БАШЛАДЫГЫЗМЫ?

Юк, бәйрәмгә иртә бит әле	48%
Кибетләрдә күзәтеп йөрим, алырга вакытыр инде	21%
Әйе, бүләкләрне алдан ук әзерләп куям	4%
Мин Яңа елга бүләк бирмим	27%

«ВТ»ның «ВКонтакте»дагы төркеменнән

ЧИКНЕ УЗГАЧ

ТАТАРСТАНДА ВИЧ-ИНФЕКЦИЯЛЕ 29450 КЕШЕ ЯШИ

Сиңа да, миңа да кагылырга мөмкин. Соңгы елларда тел очыннан төшмәгән коронавирус инфекциясе турында түгел сүз. ВИЧ-инфекция дигән чир дә юкка чыкмады бит әле. Рәсми статистикага ышансаң, Россиядә ВИЧ-инфекцияле 1188000 кеше яши. Шунысы да билгеле: ВИЧ-инфекция күптәннән бозык тормыш алып баручылар чире генә түгел инде.

«Мин кеше түгелмени?!»

Олег Рыжовка – 44 яшь. Казанда яши. Төзүче булып эшли. «ВИЧ-инфекцияле» дигән исемне берничә дистә елдан артык йөртә. Дәвалану уза.

Олегны махсус аралашу сайтларының берсеннән эзләп таптык. Үзе әйтүенчә, җитди мөнәсәбәтләр өчен хатын-кыз эзли. Мөнәсәбәтләр кору, гомумән, яңа кешеләр белән танышу андыйлар өчен аеруча авыр икән. Анысы турында соңрак.

– Дөресен әйтим, ВИЧ-инфекцияне кайда, ничек йоктырганымны инде хәтерләмим. Шунысын да яшермим: заманында бик күп эчтем дә, наркотиклар да кулландым, чоры шундый иде. Шулай булгач, көннәрдән беркөнне ВИЧ йоктыруыма аптырыйсы да түгел инде. Аптырамадым да. Моннан фаҗига ясамадым. Бала-чага түгел идем инде, – диде ул «ВТ» хәбәрчесенә. – Туганнарымның барысы да нинди икәнемне белә. Эштәгеләр дә. Ә мин яшермим дә. Мин гади кеше түгелмени?!

Олегның өч баласы да бар. Әмма ул алар белән яшәми. Һәркайсы үз тормышын корган инде. Алар да әтиләренең авыруын белә. «Балалар сау-сәламәт. Миндә «нулевая нагрузка» (вирусны контрольдә тотып була, ул бик аз күләмдә үрчи, йогышлылыгы түбән. – **Авт.**). Тернәкләнү уздым, терапия алам. Тормышымны хәзер контрольдә тотам. Хәмер эчмим, әмма тартам. Тик бик сыйфатлы тәмәке генә! Дөрес тукланам», – ди әңгәмәдәшебез.

Олег әйтүенчә, ВИЧ-инфекция йоктыру ул әле тормышыңа нокта куярга кирәк дигән сүз түгел. Киресенчә, көрәшергә, тырышырга кирәк.

– Җәмгыятьнең безнең кебекләргә карашы үзгәрде, дип уйламыйм. Әмма минем кеше фикеренә исем китми. Үзем өчен яшим! Минем төс-кыяфәтем начармы, әллә мин бозык эшләр кылып йөримме, әллә ВИЧ-инфекцияле була торып, кемгәдер зыян саламмы? Юк бит! Мин – социаль яктан бик адекват кеше, – ди ул. – Шунысы да бар: танышу, аралашу өчен мәйданчыклар юк. Махсус чат, сайтлар бар, әйе, әмма анда бозыклык шулкадәр күп! Күңел бушату, җитди мөнәсәбәтләр кору, аралашу өчен кеше табу бик авыр. Махсус төркемнәр булдырсыннар иде. Яисә безнең кебекләрне берәр нинди чарага җыйсыннар. Әйтик, кышын шугалакка. Җәен күл буена, учак ягып, җырлашып утырырга. Социаль хезмәткәрләр дә бу эшкә ныклап алынсын иде. Хәзер кешеләр болай да үз-үзенә бикләнгән. Ә безгә нишләргә?

«Төшенкелектә идем»

Хореограф Илдар Алекбаевның тарихы башкачарак. Ул тәртипсез җенси тормыш алып барган, наркотиклар кулланган кеше түгел. Чир турында, гомумән, ишеткәне дә булмаган.

– Үземдә әлеге чир булуын ишеткәч, кинолардагыча, күз алдымда томан, колакларым тонган иде. ВИЧ турында ничек белдемме? Көннәрдән беркөнне элек йөргән кызым шалтыратып: «Миндә ВИЧ таптылар. Син дә тикшерен әле», – диде. СПИД-үзәккә барып, анализлар бирдем. Мине бу урап узар дип ышандым. Әмма алай булмады, – дип сөйләде ул. – Психологиядә мәгълүматны кабул итүнең биш стадиясе бар бит әле (инкарь итү, ачулану, сатулашу, төшенкелек, кабул итү), миндә барысы да булды. Бер хәл искә төште әле. 7 нче сыйныфта укып йөргән чагым. Иптәшләрем кинотеатрга дәшә. «Анда СПИД турында документаль фильм күрсәтәләр. Әйдә!» Ә мин: «Минсез генә барыгыз. Бу миңа кагылмый!» – дидем. Кызык та, кызганыч та...

Илдар ВИЧ-инфекция белән яңадан яшәргә өйрәнгән. Белгән мәгълүматны башкаларга да сөйли, танышларга ачык, дуслары күп. «Нинди булуыңны әйтү бәйләнгән кулларны чишәргә булыша. Син үзеңә дә, башкаларга карата да гадел дигән сүз», – ди Илдар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

УЙДЫРМА	ЧЫНБАРЛЫК
Миндә ВИЧ, димәк, мин тиздән үләм?	Әгәр дәвалану узсагыз, юк. ВИЧ-инфекциянең иң соңгы стадиясе – СПИД.
Дәвалану берничә ай гына дәвам итә.	ВИЧ-инфекцияле кешегә гомере буе дәваланырга кирәк.
ВИЧ-инфекция һәм СПИД – уйлап чыгарылган чирләр генә.	Чир барлыгына ышанмаучылар һәрвакыт булган һәм булачак. Андыйларны ВИЧ-диссидентлар диләр.
ВИЧ-инфекцияле кешене эштән/уку урынынннан куалар.	Һич юк. Дискриминация закон нигезендә тыелган.
ВИЧ черки тешләве аша да күчә.	Юк, бу мөмкин түгел.
ВИЧ-инфекцияле кеше йөткерсә, төчкерсә, чир йога.	Йөткерү, төчкерү ише күренешләрдән шикләнмәгез. Чир алай гына йокмый. ВИЧ-инфекцияле кеше белән бер душта юынырга, бассейнга керергә, мунчага барырга да ярый. Киемнәрне дә алмашып кияргә була. ВИЧ-инфекция йога торган берничә юл: җенси, кан аша, әнидән – балага.

Сан

➤ Татарстанда ВИЧ-инфекцияле **29450 кеше** яши. 2023 елның 10 аенда **724 яңа очрак** теркәлгән.
➤ Республиканың **16 район**ында авыру күрсәткече республикакүләм уртача күрсәткечтән зуррак.
➤ ВИЧлы ир-атлар – **59,1%**
ВИЧлы хатын-кызлар – **39,9%**

Алинә ӘХМӘТШИНА, нейропсихолог, КФУның психология клиникасы мөдире:

– ВИЧ-инфекция йоктырган кеше белән сөйләшкәндә, шуны истә тотарга кирәк: ул кеше бездән бернәрсәсе белән дә аерылмый. Ул да – шундый ук кеше. Аның чиренә аерым игътибар бирмәскә, ни сәбәпле авыруы турында сорамаска тырышыгыз. Чир турында белемнәрегез юк икән, ул кешегә тикшерелмәгән мәгълүмат сөйләмәгез. Аны тагын да куркытырга кирәкми. Аралашу барышында күбрәк физик халәтенә түгел, хисси халәткә игътибар итү зарур. Кешегә кайчагында күңелен ачарга мөмкинлек бирү кирәк. ВИЧ-инфекцияле кешеләр билгесезлектән курка. Ни булыр? Диагноз раслангач, ничек яшәргә? Үлемнән курку да килеп кушыла. Болардан соң аңламаслар, кабул итмәсләр, кешеләр мыскыллар, рәнҗетер дип курку. Андыйларга ярдәм итү юлы бик гади – кешенең психологик халәтенә игътибар бирү һәм кирәк вакытта терәк-таяныч булу.

4 декабрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «БИЧАРАКАЙ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем…» 12+
12.00, 22.40 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней +» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 16+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «ЖЁЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Путь» 16+
01.05 «Туган җир» 12+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.10, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25, 00.40 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Туган авылым» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 3.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Баден-Баден» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
04.05 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 13.00, 14.55, 17.00, 21.30, 03.55 Новости 0+
07.05, 21.35, 00.45 Все на Матч!
09.55 Художественная гимнастика. Кубок России
12.40 Специальный репортаж 12+
13.05 «Есть тема!»
15.00 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
15.30 «Громко»
16.30, 17.05 «Коби Брайант: Чёрная Мамба» 12+
18.05 Футбол. МИР РПЛ. Обзор тура 6+
19.15 Футбол. МИР РПЛ. «Динамо» – «Рубин»
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
01.25 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. «Динамо-Ак барс» – «Ленинградка» 6+
03.25 «Что за спорт?» 12+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «ПАРМА» – МБА 6+

НТВ
04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «БАЛАБОЛ» 16+
22.15 «ЛИХАЧ» 16+
Республиканың нефть, газ һәм химия комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе, дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Премьер-министрының нефть, газ һәм химия комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе **Адиев** Эльдар Рәшит улы, Татарстан Республикасы белән күпьеллык нәтиҗәле хезмәттәшлеге һәм уртак проектларны гамәлгә ашыруга өлеш кертүе өчен «Көнкүреш техникасы үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (Мәскәү өлкәсе) **Костров** Лев Георгиевич, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен вокалчы артист (солист) **Низамов** Расим Мөхәммәт улы, прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Арча районы прокуроры урынбасары **Хәбибуллин** Радик Мөдәррис улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Хезмәт уңышларына ирешүләре һәм күп еллар дәвамында намус белән эшләүләре өчен «Вакууммаш» акционер җәмгыяте генераль директорының проект-конструкторлык эше буенча урынбасары **Данилин** Александр Сергеевич, «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең оптика цехы башлыгы **Могилюк** Игорь Антонович, «Вакууммаш» акционер җәмгыяте баш диспетчеры – план-диспетчерлык бүлеге башлыгы урынбасары **Хөсәенова** Альмира Абдулла кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Вакууммаш» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: механика-җыю производствосы җыю участогының слесаре-электромонтажчысы **Белугин** Радик Федорович, әзерлек производствосының штамплау участогы штамплаучысы **Каюмов** Азат Рәшит улына, инструментлар цехының слесаре-инструментчысы **Туманин** Евгений Николаевичка, механика-җыю производствосының җыю участогы слесаре-җыючысы **Фәрхетдинов** Эдуард Рәфгать улына **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары, эчке хезмәт полковнигы **Мөхәммәтҗанов** Фәргать Усман улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары **Гарипов** Альберт Шамил улына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе юридик факультетының гражданлык хокукы кафедрасы мөдире **Арсланов** Камил Марат улына, Татарстан Республикасының Казан нотариаль округы нотариусы, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумрессия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Гришин** Кирилл Геннадьевичка, «Төзүче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының хокук мәсьәләләре буенча урынбасары **Донской** Константин Вячеславовичка, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 номерлы районара инспекциясе башлыгы урынбасары **Дулкина** Рианна Ринат кызына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе конституциячел законнар бүлеге мөдире **Ибраһимова** Лиана Илгиз кызына, «Юл хәрәкәте имиһлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең хокукый тәэмин итү һәм персонал белән эшләү идарәсе башлыгы **Кәлимуллина** Елена Николаевнага, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 1 номерлы дәүләт кадастр исәбенә алу һәм күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәве бүлеге башлыгы **Сафина** Алсу Шамил кызына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Түбән Кама бүлеге башлыгы **Сенников** Сергей Юрьевичка, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенең юридик бүлеге башлыгы урынбасары **Шаһабетдинова** Ксения Сергеевнага **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ЙӨРӘК КАРТАЙМЫЙ

106 ЯШЬЛЕК БИБИГАМБӘР ӘБИ ҖЫРЛАП КҮҢЕЛ АЧА

80 яшенә кадәр су коенырга йөргән әле ул. 102 яшендә, балаларыннан качып, бакчага чүп утарга чыккан. Нурлат районының Каракүл авылында яшәүче 106 яшьлек Бибигамбәр әби Әхмәдиева турында авылдашлары, тиктормас, ут борчасы иде, ди. Дөрес, хәзер сикереп йөри алмый шул. Картлык тәки аяктан еккан, ул – урын өстендә. Тик кәефе булганда, җырлый әле.

Бибигамбәр, Каракүл авылы егете Госманга кияүгә чыгып, 11 бала тудырган. Тик өчесе яшьли дөнья куйган. Хәзерге вакытта биш баласы исән. Иң олы кызы Миннегайшәсе дә яшь буенча үз артыннан куып бара, аңа – 87. Әбекәй урамның икенче башында гомер кичерә. Бибигамбәр әби исә төпчеге Әкълимә (паспорттагы исеме – Гөлсирә) белән яши. Калган ике балалары да Нурлаттан ерак китмәгән. Узган ел Җиңү бәйрәме көнне 72 яшьлек улы Камил янып үлгән. Күршедә үзе генә яшәгән ул. Нәкъ менә аның бакчасына китмән тотып, чүп утарга йөргән дә инде әбекәй. Бу яшьтә бил бөгеп йөрүенә кызлары каршы булган, әлбәттә. Әмма җилкенгән йөрәкне нишләтәсең? Бер чүп тә калдырмыйча, бакчаны ялт иттереп куйган. Сыерны да сиксәнгә кадәр тоткан. Аптырагач, кызлары: «Җитте инде, әни, күпме эшләргә була?» – дип, сөтлебикәне күрше авылга илтеп тапшырган.

– Унбер баланы табып, үстерү өчен зур сабырлык кирәк. Күз алдына китерегез: әни ун ел буе көмәнле килеш йөргән дигән сүз бит ул! Олы апам минннән 21 яшькә олырак. Аның улы Васил белән бергә укыдык, – дип елмаеп куйды 66 яшьлек Әкълимә ханым. – Моңа кадәр ярдәм кирәк булмады әнигә. Үзе ашады, эчте, урамга чыкты. Соңгы вакытта ризыкны блендерда ваклап ашата башладым. Күптән шулай кирәк булган икән. Ашказаны авыртуы бетте. Нәрсә бирсәм, шуны ашый. Итле ашын да, сөтле ризыкларны да. Әни картаюдан туктады кебек тоела миңа. Хәле алга да бармый, артка да китми. Гел бертөрле. Бергәләп мунча керәбез. Күтәреп алып барырга туганнар булыша. Рәхәтләнеп юына: хәле дә бетми, кан басымы да күтәрелми, күз тимәсен.

Авыл кешеләре әбекәйне бик юмарт кеше, бик оста йөзә иде дип искә алды. Тумышы белән Салдакай авылыннан ул. Менә шунда Чирмешән елгасында коенып үскән. Каракүлне исә авылда кечкенә Байкал диләр. Менә шунда барып, җәйге челләдә су коенган. «Кая, читкә китеп торыгыз әле», – дигән дә, рәхәтләнеп, колач җәеп йөзгән. Сиксән яшь җиткәндә, кайсы авыл әбиенең су кергәнен күргәнегез бар әле? Озын гомерле булуының сере тормыштан тәм табып яши белүеннән дә киләдер, мөгаен. Ул гына да түгел, икенче буын туганнары арасында гасыр кичүчеләр дә бар икән. Димәк, нәселдәнлек тә үзенекен итә.

Бибигамбәр әбинең көне караватта уза хәзер. Әмма кызы әнисенең картлыгына ямь өстәргә, күңелен күтәрергә тырыша. Өй тирәсендә эшләре беткәч, тавыклар ашаткач, аны җырлатырга да вакыт таба. Бергәләп «Утыр әле яннарыма»ны җырлыйлар. Әкълимә апа, «Бие, бие, Хәйбулла»ны такмаклый, кулы белән әнисенең аякларын тыпырдаттыра. Бераз булса да хәрәкәтләнсен,

Зөлфия Хәлиуллина

Бибигамбәр әбинең төпчеге – Әкълимә апа.

язылсын, диюе. Без әбекәйгә күпме генә сорау бирсәк тә, дәшмәде. Әллә ишетмәмешкә салышты шунда. Ә менә кызынықын бик тиз ишетте. Үзенеке бит! Йөз яшьтән узган әни белән яшәүче кызның тормышы шундыйрак. Баласының уфтанмыйча тәрбияләвен тоя, сизә ана йөрәге.

Сан

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы 22 ноябрьгә китергән мәгълүматларга караганда, республикада **100 яшь**лек һәм аннан да өлкәнрәк **215 кеше яши**. Шуларның **20**се – ир-ат, калганнары – хатын-кыз.

КҮРГӘНЕ – БИЗӘК

Балтач районының Куныр авылында яшәүче Гөлшат Шәрәфетдинованың кул эшләрен кайлардан гына сорамыйлар: Әлмәт, Чаллы гына түгел, Чиләбе, Мәскәү шәһәрләреннән дә. Сөлге, мендәр тышлары, намазлыклар да чигә ул.

– Хезмәтләремне социаль челтәрләргә дә куйгалыйм. Шуннан күреп, заказ бирәләр, – ди Гөлшат Шәрәфетдинова.

Чигү белән тугыз ел элек мавыгып киткән ул. Дөресрәге, күңелен клуб мөдире, бергә уйнап үскән иптәш кызы Разыя җилкеткән. Мәдәният йортына милли киемнәр тектергән, концерт куйган болар. Шуннан соң ахирәте: «Йә, ничек?» – дип, Гөлшаттан фикерен сораган. Дусты инде нәрсә уйлаган, шуны әйткән. «Бик әйбәт булды, әмма ак алъяпкыч, яулыкларның читләрен чигәсе бар», – дигән. Кыскасы, бу эшне үзенә кушкаННАР. Ул вакытта шәфкать туташы булып эшләвенә карамастан, ризалашкан Гөлшат.

– Махсус эзләп тә йөрмим, бизәкләр үзеннән-үзе каршыга чыга. Фотога төшереп алам да, өйгә кайткач, шул үрнәкне ясыйм. Бусы – мендәр тышына, ә монысы сөлгегә туры килә икән дип, алдан уйлап куям. Әле шундый гадәтем бар: бер чиккән үрнәкне икенче мәртәбә кабатларга яратмыйм. Миңа гел яңа әйбер кирәк. Илһам килсә, әллә нәрсәләр майтарырга була, – ди Гөлшат ханым.

Элек күбрәк кулъяулыклар чиксә, хәзер мендәр тышлары, сөлгеләргә күчкән. Намазлык сораучылар да күп икән.

– Табышына кызыгып чигүем түгел. Һәр хезмәт түләнергә тиеш дип кенә акча алуым. Туганнар, дусларга бүләк итәм. Пенсиядә тик ятып булмый бит. Телевизор карарга яратмыйм. Үзенә күрә бер шөгыль , – ди Гөлшат Шәрәфетдинова.

ОСТАЗЫ – ИНТЕРНЕТ

«Ясый-ясый шомарасың», – ди Илмир.

Мамадышта яшәүче 27 яшьлек Илмир Нәҗметдинов тракторлар ясау белән мавыга. Икесе әзер икән иде, өченчесе дә озак көттермәс. Механик та, инженер да түгел ул, махсус белеме дә юк. Егет барысына да интернет ярдәмендә өйрәнә. Барып чыкса, трактор сатып, акча эшләү хыялы да бар.

– Үзем уйлап тапкан техника түгел ул, – ди Илмир. – Хәзер бит интернеттан карап, әллә ниләр кыландырырга мөмкин. Кирәк-яракларын тапсаң, бернинди авырлыгы да юк. Тимерләрне кибеттән, металл тапшыру пунктларыннан сатып алам. «Ютуб»тагы белгечләр тракторны ничек ясарга икәнлеген өйрәтә. Мәктәптә математика, физиканы әллә ни яхшы укымасам да, ике тракторны да ахырга кадәр башкарып чыктым. Иң мөһиме – теләк.

Егет әйтүенчә, сатып алу – бер нәрсә, ә үз кулларың белән ясау бөтенләй икенче инде. «Ясый-ясый шомарасың. Бер хатаны икенче тапкыр кабатламыйсың», – ди ул.

Мәрхүм әтисе тракторчы булса да, кечкенә чагында Илмирнең техникага әллә ни исе китмәгән. Аның һөнәре – эретеп ябыштыручы. Техникум тәмамлагач, Мамадыш кирпеч заводына оператор булып эшкә урнашкан. Башына операция ясаткач, эштән китеп торырга туры килгән. Әмма тик утырып булмый бит инде. Трактор ясау – шөгыль дә, рәхәтлек тә бирә. Җае чыккан саен, әнисенең туган авылы Кече Кирмәнгә кайтып йөри. Мәрхүм әби-бабасының нигезенә сукмакны суытмый.

Ясаган тракторлары әби-бабасының ишегалдында тора. Беренче тракторын моннан өч-дүрт ел элек шәһәрдән авылга кайта-китә ясаган. Моның өчен 1,5 ел вакыт кирәк булган. Кечкенә тракторы белән бакча сукалый, йорт тирәсендәге вак-төяк эшләрне башкара. Икенчесенә чүмеч таккан. Анысы – кышын кар эттерү, ташу өчен. Тиресне дә кул белән түкмиләр хәзер. Күрше-тирәгә булышырга да җай таба егет. Өченчесен бар эшкә ярарлык итеп көйләргә җыена. Ә хыялы – чылбырлы трактор ясау.

Киләчәктә техника сатып, акча эшләү уе да юк түгел. Сораучылар бар, әмма бәясен кыйммәтсенәләр икән. Илмирнең исә үз фикере: яхшы техника арзан булмый, 150–200 мең сумнан да арзанга бирмәячәк.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

ХУШ, ӘНИ!

НАИЛӘ ГӘРӘЕВАНЫ СОҢГЫ ЮЛГА ОЗАТТЫЛАР

kamalteatr.ru

Камал театрының тагын бер якты йолдызы сүнде. 60 елдан артык гомерен татар театры сәнгатенә багышлаган, йөрәген сәхнәгә биргән актриса, театр яшьләренең «дәү әнисе», остаз, сөекле әни. Казанда Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Наилә Гәрәеваны соңгы юлга озаттылар. Хушлашу мәрасиме Мәрҗани мәчете каршында узды.

Актрисаны соңгы юлга озатырга туганнары, хезмәттәшләре һәм йөзләгән тамашачысы килде. Хушлашу мәрасимен Татарстанның халык артисты Илдар Хәйруллин алып барды.

– Наилә Гәрәева театр сәхнәсенә якты йолдыз булып балкып, очып керде дә 60 елдан артык җанын, күңелен биреп иҗат итте. Үзенең иҗаты белән татар театрының дәрәҗәсен, абруен күтәрде. Күптөрле образлар тудырып, татар сәнгате күгендә якты маяк булды, халкыбызның күңелендә лаеклы урын алды, – диде ул. – Наилә Хәкимовна бик тынгысыз, эзләнүчән кеше иде. Һаман эзләнде, һаман чапты, иҗат итте. Егерме биш ел буена укытты, яшь артистлар әзерләде. Бүген бөтен театрларда да аның шәкертләре бар. Ул башлаган эш дәвам итә. Алар тудырган чор – бөек чор. 60, 70, 80 нче еллардагы бөек чор китеп барса да, аларның истәлеге, аларның хезмәте белән театрыбыз гөрләп эшли, яши.

Мәрхүмәне озатырга Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов та килгән иде.

– Татар театр сәнгатенең иң якты йолдызларының берсе белән хушлашабыз. Репертуарында 100дән артык роле булган Наилә апабызны аның меңләгән, бәлки йөз меңләгән тугры тамашачысы, Камал театры сәхнәсе әле озак еллар сагынып, юксынып яшәр. Алтмыш елдан артык иҗат чорында ул театр белән бер җан, бер гаилә булып яшәгән. «Беренче мәхәббәт» әсәрендәге беренче роле Рәхилә образы аша тамашачының гомерлек мәхәббәтен яулаган, яшьләрнең кумирына әйләнгән. Ул вакытта орчык кадәр генә ут күзле чибәр кызга гашыйк булмаган егет калмагандыр. Татар кызларының күбесе аның кебек киенеп, аңа охшарга тырышып яшәгәннәр, дип сөйлиләр, – диде Марат Әхмәтов. – Бүген Наилә апаның традициясен улы Фәрит Бикчәнтәев уңышлы дәвам иттерә. Наилә апа улын милли җанлы, милли рухлы итеп тәрбияли алган. Камал театры сәхнәсе – милләтнең көзгесе. Фәрит Рәфкатович бу сәхнәдә олы җаваплылык тоеп, коллективны бер гаилә итеп туплап, эшне уңышлы дәвам иттерә. Сезнең өчен бүгеннән авыр, ятим, әнисез көннәр башлана. Әнисез калуны беренинди тормыш кыйммәтләре дә алыштыра алмый. Халыкта шундый сүз дә бар: әни китү аяк астыннан җир китү белән бер. Сезгә сабырлык һәм ныклык телибез. Әниегезнең рухы сезгә иҗат эшчәнлегегездә аның традицияләрен матур дәвам иттерергә көч-куәт бирсен.

«Театрдагы яшьләр өчен дәү әнигә әйләнде. Игътибарлы, кайгыртучан, юмарт, таләпчән һәм бик нечкә күңелле иде». Татарстанның халык артисты Луара Шакирҗанова мәрхүмә белән соңгы очрашуларын искә алды:

– 17 октябрьдә Наилә апа театрның кече залында «Исәнме, улым» спектаклендә уйнарга тиеш иде. Ул көнне бик хәлсез, бик кәефсез иде. Спектакль башланды, залга кердем. Һәм мин шунда бөтенләй башка Наилә апаны күрдем. Артистның шулай үзгәрә алуына шаккаттым. Ана образын, гадәттәгечә, тулы канлы итеп башкарды. «Сәхнә шулай бит ул, көч бирә», – диде. Әйе, сәхнә көч бирә, ләкин ул көчне ала да торгандыр. Наилә апаның соңгы көчен биреп уйнаган соңгы киче иде. 18 ноябрьдә туган көне белән котлап шалтыраттым. Өмете яшәүдә, көрешүдә иде. Рәфкать абыйның февраль аенда булачак 100 еллыгы турында уйланды, борчылды. «Бәрәскәдә дә уткәрергә кирәктер», – диде. Ул Рәфкать абыйның туган ягы Бәрәскәне, Әтнә төбәген бик якын күрде, кешеләрен яратты, гел кайтып йөрде. 83 яшькә кадәр сәхнәдә булган бәхетле актриса һәм бәхетле кеше иде. Театрыбыз Наилә апаның икенче, ә бәлки, төп йорты булгандыр.

«Тумышы белән Казаннан булса да, күңеле, бөтен җаны белән Әтнәнең Бәрәскә авылыныкы иде». Бусы – Әтнә районы Башкарма комитеты җитәкчесе Айрат Каюмов сүзләре.

– Наилә апа авыл тормышы белән яшәде, шатлыкларыбызга сөенде, кайгыларыбызга көенде. Бәрәскә авылына бик күп игелекләр кылды. Гади авыл балаларын данлыклы Камал театры сәхнәсенә менгерде. Авылда, районда булган бик күп чараларда катнашты. Әтнә театры белән гел элемтәдә булды. Наилә апаның якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр, – диде ул.

Наилә Гәрәева Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнде.

Ләйсән САФИНА

ТАИФ төркеме коллективы, әнисе – Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган артисты
Наилә Хәким кызы ГӘРӘЕВАның
кинәт вафат булуы сәбәпле, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры Фәрит Рәфкать улы Бикчәнтәевнең авыр кайгысын уртаклаша.
Наилә Хәким кызы Татарстан һәм Россиянең сәхнә сәнгатенә бәһаләп бетергесез өлеш керткән күренекле актриса, легендар мәдәният эшлеклесе буларак хәтеребездә уелып калачак. Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланачак.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ



ГӘРӘЕВА НЭЛЛЯ ХӘКИМ КЫЗЫ (НАИЛӘ ГӘРӘЕВА)
(18.11.1940 – 28.11.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Татар театрының күренекле артисты, Россия Федерациясенең – атказанган, Татарстанның халык артисты 28 ноябрь көнне 84 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Наилә Гәрәева 1940 елның 18 ноябрендә Казан шәһәрендә туган. 1961 елда Качалов исемендәге Зур драма театры каршындагы студияне тәмамлаганнан соң, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры труппасына кабул ителеп, 60 елдан артыграк вакыт дәвамында шунда хезмәт куйган.

Ул тәүге тапкыр икенче курста укыганда сәхнәгә менгән: «Беренче мәхәббәт» спектаклендә катнашкан. Актриса тудырган Рәхилә образы, тиңдәшсез таланты, мөлаемлыгы һәм хиссилеге белән, Наилә Гәрәевага гаять зур популярлык китергән. 60 нчы еллар ахырында иң уңышлы хезмәтләреннән берсе – Чыңгыз Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» повесте буенча куелган спектакльдә Әсәл образы да бик югары бәяләнде: бирегдә ул йомшак күңелле, шул ук вакытта көчле рухлы кызның үтә катлаулы кичерешләрен бик оста итеп күрсәтте.

Наилә Гәрәева, Татар академия театрының данлыклы коллективы тарихын гәүдәләндереп, татар актерлары мәктәбенең иң яхшы традицияләрен үзенә сеңдергән чын сәхнә остасы иде. Үзенчәлекле, күпкырлы таланты, еллар узган саен арта гына барган бетмәс-төкәнмәс иҗади илһамы аңа дөнья, рус һәм татар классикасы спектакльләрендә, шулай ук заманча драматургия әсәрләрендә 100дән артыграк төрле образлар тудыру мөмкинлеге бирде.

Тамашачыларның төрле буыны аның бик күп күркәм образларын күңеленә сеңдерде. Алар арасында – Зөбәйдә («Зөбәйдә – адәм баласы»), «Әни килде» (Әни), Гөлтәкин («Айдын»), Зөбәрҗәт («Ай тотылган төндә»), Диләфрүз («Диләфрүзгә дүрт кияү»), Миләүшә («Дуслар җыелган җирдә»), Миләүшә («Хушыгыз!»), Әнҗе («Кол Гали»), Бибкәйнур («Кыю кызлар»), Күрше («Бичура»), Сабира («Зәңгәр шәл»), Шәмсия («Казан сөлгесе»), Анфиса («Өч сеңел»), Абруй – («Мәхәббәт турында сөйләшик»), Хәлимә Әмировна («Көттереп килгән җәй»), Әни («Саумы, әни, бу мин!»), Миңниса («Әтәч менгән читәнгә») һәм башка бик күп образлар.

Наилә Гәрәеваның тормыш юлы һәм гаиләсе актерлык һөнәренә иксез-чиксез тугрылык үрнәге булып тора. Ул 20 елга якын Казан дәүләт мәдәният институтында һәм Казан театр училищесында яшь буынны укыту, тәрбияләү эшчәнлеген алып барды.

Наилә Гәрәеваның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Дуслык», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденнары, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, Габдулла Тукай исемендәге ТАССР Дәүләт премиясе.

Наилә Хәким кызы, тамашачысының иксез-чиксез мәхәббәтен яулап, гомеренең соңгы көннәренә кадәр үз эшенә тугрылыклы булды. Күренекле актрисаның күпкырлы иҗаты, милләтебезнең гомуми казанышына әйләнеп, татар театр сәнгатендә кабатланмас эз калдырды.

Сөекле артистыбыз, талантлы кешенең якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, М.Г. ӘХМӘТОВ, И.Р. МЕТШИН, И.Х. ӘЮПОВА, Р.Р. ЗӘЙДУЛЛИН, Ф.Р. БИКЧӘНТӘЕВ, Р.Ш. ӘХМӘДИЕВА, Р.Р. ТАҖЕТДИНОВА

МАРИНА САПУРИНА: «ЙӨРӘК БАРЫСЫНА ДА ТҮЗӘ ИКӘН»

Язылганга кире кайтып

Көньяк Кореяга эшкә киткән 27 яшьлек Венера Сапуринага кире туган якка исән-имин кайтырга насыйп булмады. Чит җирдә бәлагә тарыган якташыбыз турында «ВТ»ның алдагы саннарында бәян иткән идек инде. Ул чакта Венераны дәвалау һәм Татарстанга алып кайту теләге белән акча да җыйдык. Тик насыйп булмады. Самолет белән кайтарырга рөхсәт бирә торган анализны көткәндә, Венераның үлгән хәбәре килде.

10 октябрьдә вафат булган кызның көлен 25 ноябрьдә Әниләр көне алдыннан Мамадыш районының Владимир авылында җирләделәр. «ВТ» журналисты Сапуриннар гаиләсенә кайтып, кайгыларын уртаклашты, аларның якыннары белән аралашты, Венера белән саубуллашты.

Тел белмәү азаплады

Исегезгә төшерик: Венера чит илгә өч ел элек китә. Иптәш кызларының барып эшләп кайтканын күргәч, ул да юлга кузгала. Чит телләр белә, кеше белән аралашырга ярата. Бик чая була. Әнисе Марина апаның гына кызын бер дә читкә җибәрәсе килми. Тик Венера үзенчә хәл итә. Аэропортка барып җиткәч кенә, мин Кореяга китәм, дип әнисенә хәбәр сала.

– Ул чакта бер дә начар уйламадым инде. Баламның теләгенә каршы килеп, нишли ала идем соң, ризалаштым. Көн дә сөйләшеп тордык. Бар да яхшы иде. Кызым мине туган көнемә үз янына чакырды. «Чит ил паспорты ясата башла, сентябрьдә монда килерсең дә аннары бергә кайтып китәрбез», – диде кызым. Тик язмыш башкача хәл иткән икән, – ди Марина апа.

Соңгы тапкыр кызы белән 7 июньдә сөйләшә алар. Венера бернидән дә зарланмый. Ә инде 8 июнь иртәсендә Марина апага шалтыратып, кызыгыз үлем хәлендә, күреп калырга килегез, диләр. Нишләргә белмәгән ана юлга әзерләнә башлый. Тиз арада чит ил паспорты ясата, акча юнәтә дә 22 июньдә кызы янына килеп төшә.

– Мин килгәндә хәле авыр иде. Күзләрен ачып караса да, берни әйтә алмады. Аңлап ятты балакаем! Эндәшә алмагач, елый иде. Әле дә күз алдымда мөлдерәп аккан яшьләре тора. Кулларымны кысып тота иде. Терелер, дидем. Баштарак кызымның хәле авыр икәнен берәүгә дә әйтмәдем. Янәсе, табиблар аякка бастыра да туган якка кайтабыз, – ди Марина апа. – Ә монда дәвалану бик кыйммәт булды. Түләр өчен Венераның Казандагы фатирын саттык. Әтисе исемендә иде ул. Шуңа сата алдык. Шул акча җитәр, башка кирәкмәс, дип уйладым. Тик булмады. Үзебезнең көчтән килми башлагач кына бу хәлләрне дөньяга чыгардым. Анда безнең кебек кешеләргә, кая барса да, акча кирәк. Тел белмәү дә харап итте. Кеше һич югы бер чит тел өйрәнсен икән. Соңга таба андагы табиблар мине сүзсез дә аңлый башлады. Ничек өзгәләнүемне күрәләр иде бит. Хәлемә керүчесе күп булды.

«Венера кайтып керер төсле», – ди әнисе Марина апа.

Кулларымда – көле

Венераның җәсәден алып кайту бик кыйммәткә чыгасын белгәч, Сапуриннар кремация ясарга ризалык бирә. Анысына да бик күп суммада акча таләп ителде. Яндыру өчен чират булгач, гәүдәсен моргта тоту өчен дә түләргә кирәк булды. Әле ярый, «ВТ»да язма чыккач, үтенечебезне тыңлап, блогер Гөлия Вәлиәхмәтова акча җыярга булышкан иде. Марина апаның үз картасына да акча күчерүчеләр булды. Ул көннәрдә без гел элемтәдә булдык.

– Кызымның җәсәден яндыргачы, аны матур итеп киендерделәр. Бизәнделәр дә әле. Ничекләр түзгәнмендер инде бу хәлләргә? Минем йөрәк теткәләнеп беткәндер... Башта, яндырганны туганнарга күрсәтермен дип, видеога да төшермәкче идем. Ярамый икән. Мине анда кертмәделәр. Бик авыр халәттә идем, – ди Марина апа. – Соңыннан чакырып алып, кулыма ак перчатка кидереп, баламның махсус савытка салынган көлен тоттырдылар. Әле ул кайнар иде. Аны үзем торган фатирга алып кайтып куйдым. Төшләремә кер, балам, дип тә үтендем. Тик кермәде...

Аның каравы әтисенең әнисе Екатерина түтинең төшенә керә Венера. Моннан биш ел элек үлгән бабасының куенында утыра икән. «Венерам гел мин иде инде ул», – ди Катя түти.

– Гел кайтып йөрде. Син утырып кына тор, әби, үзем эшлим, дип әйтә торган иде. Монда кайткач, тәмле ризыктан өзмәде. Чая булды ул. Бик башлы да иде. Бервакыт абыйсы математикадан дәрес эшли алмый. Ә ул дүрт яшендә аңа кушып, алып бирә. Әрәмнәр булды инде балабыз, – ди әбисе. – Елап кайтарып булмый. Түзәргә, чыдарга, сабыр итәргә кирәк. Барыбыз да анда барасы. Кем кайчан бара инде... Венерамның гомере бигрәк кыска булды.

Венера әтисен дә бик яраткан. Александр абый да баласы белән гел телефон аша сөйләшеп торган. Соңгысында Венера: «Мин сине бик яратам», – дигән аңа. Әтисе дә: «Мин дә яратам, кызым», – дип җавап биргән.

– Венераның үлемен ишеткәч, өзгәләндем инде. Әллә ничә төн күзгә йокы кермәде. Кайтыр төсле иде. Тик булмады. Бик авыр хәсрәт. Алга таба ничек яшәргә?! – ди ул.

Ана йөрәге

Аңа бар да сыя. Ярату, сагыш, сызлану. Марина апа кызының кырыгын да укыткан инде. Үз диннәренчә, йоласына туры китереп җирләсә дә, әле дә күңеле ышанмый үзенең. Венерасы исән төсле. Күбәләккә әйләнгәндер, ди ул аны. Кореядан кайтканда ул утырган утыргыч янындагы тәрәзәгә кинәт кенә күбәләк килеп куна. Кайтып җиткәнче, Марина апа шул күбәләккә карап бара. Аның белән сөйләшә дә әле.

– Венерамның җаны булгандыр ул. Самолет туктауга юкка чыкты бит. Мине шулай озатып кайтты булгандыр, – ди Марина апа. – Күңелемдә бер генә теләк: мин кичергәннәрне бер анага да кичерергә язмасын! Чит илдә азаплануымны белсәгез иде. Ахырга кадәр баламны яшәтә алырбыз дип өметләндем. Тик булмады. Вакыт – дәва, диләр. Юк. Торган саен күңелем айкала. Баламның кечкенә чаклары, буй җитүе, азапланып ятулары күз алдымда тора. Үзем үлгәнче оныта алмаслык ярам бу. Газета аша безгә ярдәм иткән һәркемгә рәхмәтемне җиткерәм. Үз игелегегез меңе белән үзегезгә әйләнеп кайтсын.

...Без дә өметләндек. Венераны туган якка кайтару юлларын эзләдек. Зур түрәләргә дә мөрәҗәгать иттек. Бар да яхшы булыр кебек иде. Тик булмады. Сапуриннар гаиләсенә килгән хәсрәт бик күпләрне борчыды. «ВТ» укучыларына без язган язмышларга битараф булмаганнары өчен, Марина Сапуринаның хәлен сорап шалтыраткан, хатлар язган өчен зур рәхмәт. Без исә бу гаиләнең авыр кайгысын уртаклашабыз. Кызыгызның рухы шат булсын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

Кайсыгызның кулы җылы?

Терелтәсе килә

Зәй районының Төги авылында туып-үскән Венера Ушенкинаны 3 яшендә машина бәрдерә. Балачагы хастаханәдә уза аның. «18 яше тулганчы ярдәм итеп торырмын», – дип антлар эчкән машина йөртүче дә юкка чыга.

– Аякларымның берсе кыскарак иде, бик авырлык белән култык таяклары тотып йөрдем. Зәй политехник көллиятендә белем алганнан соң, сәламәтлегемне кайгыртырга булдым, – дип сөйли Венера. – Барлыгы 18 катлаулы операция кичерергә туры килде. Инде төзәлеп бетә дигәндә, аякларым ялкынсынды, бер аягым бөгелми башлады. Яңадан мускул өстәделәр. Мин кабат операциягә барасы идем. Тик Аллаһы Тәгалә миңа зур бүләк әзерләгән булып чыкты.

Биш ел култык таяклары белән йөргән кыз бу вакытта кияүгә чыккан була инде. Бәби көткәнен белгәч, бөтен тормышы үзгәргәндәй була. Авырту-сызлаулар онытылып, әйтерсең, күктән бәхет яңгыры ява. Әмма тагын сынау язган икән. Венераның балага узуын белгәч, ире ташлап китә. Венера йөклелекнең сигезенче аена кадәр эшләп йөри. Инвалидлык буенча түләнә торган 14 мең сум пенсиягә генә җан асрап буламы соң?! Җитмәсә, яраткан кешесенең ташлап китүе, түләүле анализлар өчен акча табу... Өзгәләнгән чаклары күп була аның. Әмма әни булу теләге көч өсти аңа.

– Тугыз ай буе култык таягы белән йөрдем. Җиңел булмады. Табиблар да баланы күтәреп бетерә аласыма ышанмады. Шөкер, улымны вакытында таптым. 3 килолы булып туды ул, – ди Венера.– Балам тугач, тормышым үзгәрде. Ничек тә яшәргә, бирешмәскә кирәк, дидем. Юлымда бик яхшы ир-ат очрады. Ул мине балам белән кияүгә алды. Төп таянычым, кая барсам да, ярдәм итүчем – ул.

Бар да яхшы, дип торганда, табиблар баланың аяклары кәкре булып туганын әйтә. Аңа операция ясыйлар. Тик ул уңышлы чыкмый. Тагын операция кирәк. Бу юлы түләүле, 120 мең сум акча сорыйлар икән.

– Үземнең аякларым сау-сәламәт булса, баламны табибларга йөртеп, инвалидлык та алыр идем. Андый очракта бу операцияне бушлай да ясыйлар икән. Әмма минем моңа хәлем юк. Вакытны да сузасы килми. Балам мин күргәннәрне күрмәсен иде, – ди Венера. – Шуңа да мәрхәмәтле кешеләрдән ярдәм сорыйм.

Венера Хәмит кызы Ушенкина исемендәге

2202 2067 1641 7071

Саклык банкы (Сбер) картасы 89828052559 номерына беркетелгән.

ФИРЗӘР МОРТАЗИН:

«ӘЛЕ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ҖЫРЧЫГА КАРШЫ ЧЫГА АЛАМ»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авылда яшәгән иҗат кешесенең тормышка карашы үзгә. Аңарда ашыгу, борчылу, вакыт санау юк. Бәлкем, шуңа иҗатлары үтемлерәк, үзләре халыкка якынрактыр да. Татарстанның халык артисты, композитор Фирзәр МОРТАЗИН да туган авылында яши. Аның белән авылда яшәү фәлсәфәсе, иҗат һәм эстрада хәлләре турында сөйләштек.

:: Фирзәр абый, сез туган ягыгызда – Буа районының Кайбыч авылында яшисез. Казаннан читтә яшәүнең нинди өстенлеге һәм нинди кыенлыклары бар?

– Казанда сигез ел яшәгәннән соң туган авылга күчендек без. Бер кайтканда минем өйдән дә ерак булмаган, хатынымның туган йорты белән янәшә диярлек бер урын карап куйдык та тәвәккәлләдек. Каланың шау-шуы тәмам алҗыткан иде, тынычланып, иркенәеп калдык. Йортны өч ел җиткездем. Казанда кайнау кирәкми дип, бәлкем, яшь чакта, чыннан да, башкалада яшәргә кирәк булгандыр. Хәзер инде, яшьләр әйтмешли, без – «неформат»лар *(көлә)*. Алар «неформат» диләр инде, ләкин әле мин аларның любоена каршы ярышырга чыга алам. Мактанып әйтмим, дөресе шул. Авыл бит ул иҗатны чикләми. Чакырсалар, Мәскәүгә дә барабыз, Казанга да. Әмма 65не тутыргач, иҗат дип бик чиләнәсе дә килми. Яшь барган саен, ялкаулык та өстәлә торгандыр. Ә авылны яратам мин. Җирдә казынмыйча тора алмыйм. Инеш буенда яшәгәч, казлар асрамау – гөнаһ. Каз-үрдәк, тавык-чебеш тә бар, кәҗәләр дә тотабыз. Казларга инешкә төшеп йөрергә 200 төп тирәсе каен утыртып, аллея ясадым. Кәҗә үзенә бер мавыктыргыч мал булып чыкты. Мәсәлән, кәҗә кызларын вакытында кияүгә биреп алырга кирәк. Андый чакта машинага төйим дә кияү йортына илтәм. Илтмәс тә идең, кычкыруларына чыдар хәл юк. Алар инде хәзер миндә дүртәү. Нәрсә өчен асрый башладыгыз, дисәгез, әлеге дә баягы сәламәтлекне кайгыртып. Онык диатез белән интекте. Сыер сөте ярамый, ул ярамый, бу ярамыйдык. Шул чакта бер кәҗә алып карарга булдык. Бу мал үз бәясен бер айда аклый икән. Хәзер инде без кәҗә сөтеннән каймак, катык, кортына кадәр ясыйбыз. Менә шулай, яхшы яклары күп авылда яшәүнең. Үзем үстергән сыйфатлы ризыклар белән генә тукланам, саф һава сулыйм. Олыгая барган саен, әнә шул якларга да игътибар итәсең икән ул.

:: Күченеп кайткан кешедән, гадәттә, авылга нинди яхшылык эшләдең, дип сорыйлар.

– Хәзер авылга яхшылык эшли торган кеше кайтмый *(көлә)*. Мин кайткан шәпкә ел саен балаларга Сабан туе оештыра идем. Безнең бүләкләр район Сабан туенынкына караганда да шәбрәк булды. Дуслар да бик булышты. Аннары төрле сүзләр ишетелә башлады. Имеш, Фирзәр Сабан туе акчасына Төркиягә ял итәргә йөри икән. Юкса районнан да, халыктан да акча җыйган булмады. Матур уза иде бәйрәм, әмма аңа беркайчан да район җитәкчеләре килмәде. Тора-бара минем дә күңел сүрелде. Хәзер җитәкчелеккә башка төрле, мәдәниятка илтифатлы егетләр килде. Әгәр сорыйлар икән, авыл өчен дә, район өчен дә көчне кызганган юк. Хәзер менә отчет концерты булырга тора. Килеп чакыргач, ничек бармыйсың – җырлап кайтам, Алла боерса. Ел саен гыйнварда, туган көнемә туры китереп, Буада концерт куям. Быел ул 21е булачак. 24 гыйнварда Чаллыда, 30 гыйнварда Казанда, «Пирамида» күңел ачу үзәгендә концерт куярга исәп.

:: Элеккеге эстрада белән хәзерге арасында аерма зурмы?

– Бездә эстрада элек тә юк иде, хәзер дә юк. Бу яктан без бик артта калганбыз. Бер көнне телевизордан Илһам Шакиров концертын карадым, шатландым шуңа. Чөнки ул инструменталь ансамбльгә кушылып җырлады. Бездә ул юк. Бездә флешка алып киләләр дә, инструменталистларын бутафория итеп чыгарып бастыралар. Җанлы музыка булса, әйбәт булыр иде дә бит ул. Ә ни өчен алай түгел? Сәбәбе бик гади: бездә рус артистлары концертларындагы кебек билет бәясен 15–30 мең сум куеп булмый. Бәяне шулай куймыйча гына аппаратурага, ансамбльгә, транспортка һәм башкасына түгелгән чыгымнарны каплап булмый. Рус эстрадасында концертларның спонсорлары бар, бездә әле бу юк. Шуңа күрә безнең эстрада бер кулланышлы шприц кебек. Бүген бар, иртәгә юк.

Элек радиога җырларга бара идек. Бормада аз гына хата җибәрсәң дә, кире кайтарып җибәрәләр. Хәзер акчаң гына булсын, радиосы да, телевидениесе дә үзе чакырып тора.

> Бүген яшь җырчыга бик авыр. Сәхнәгә чыгам дисә, җырны сатып алырга кирәк. Радио-телевидениегә ротация чыгымнарын да кертеп исәпләгәндә, ким дигәндә 150 мең сум акча китә. Эстрадада гына түгел, барлык өлкәдә дә талантлы кешеләргә үз урынын табу кыен, менә шунысы кызганыч. Заман – уртакуллар һәм талантсызлар кулында.

:: Яшь чакта пиар кирәк идеме?

– Кирәкме, кирәкмиме – мине матбугат бик шәп «пиарить» итте. «Мондый җырчы булмый», – дип яздылар. Мине яратмаган җырчылар бозауларына Фирзәр дип кушкан дип тә ирештерделәр. Кара янәшәсендә ак булган кебек, күреп алучылар, ярдәм итүчеләр дә булды. Композитор Ганс Сәйфуллинга рәхмәтлемен. «Фирзәр, сине сүгәчәкләр дә, кысрыклап чыгарырга да тырышачаклар, төшенкелеккә бирелмә», – дип, алдан ук кисәтеп куйды. Син үзенчәлекле, дип үсендереп торды. Булды инде: «профнегодный» дип, «Татар җыры»ннан төшереп калдырдылар. Шул ук вакытта Спорт сараенда, Цирк бинасында шыгрым тулы залларга концертлар куйдым. Ә конкурсларны бервакытта да яратмадым. Катнашырга да, жюрида булырга да теләмәдем. Чөнки анда бервакытта да объективлык саклана алмый. Үпкәләсәләр үпкәләсеннәр, әмма дөреслек юк аларда. Хәер, сәнгатьтә генә түгел, бөтен җирдә шулай.

:: Җырлама әле, Фирзәр, көйләр генә яз әле, дип әйткәннәре бармы?

– Күземә карап әйткәннәре юк, бәлки, арттан сөйләнгәннәрдер. Бөтен кешегә дә ошап бетеп булмый, бу табигый. Кайчакта җыр язып, шуны баянда уйнаганны видеога төшереп, дуслар социаль челтәргә элгәлиләр. Анда киресенчә: «Сагындык, тагын уйна, тагын җырла, Фирзәр», – дип язалар.

:: Автор өчен тагын бер авырткан тема: авторлык хокуклары мәсьәләсе. Сезнең җырлар популяр. Шул популярлыкның әҗерен күрәсезме?

– Минем хәлем начар түгел, бу җәһәттән зыян күргән авторлар шактый. Җырчылар хәзер килешү белән җыр алырга ияләнеп китте. Бу инде – бөтен хокукларыңнан колак кагасың, ул шул җыр белән акча эшли, син коры каласың дигән сүз. Дусларга мин болай да сатып бирмим анысы. Кирәк чакта аларга – мин, аннары алар миңа ярдәм итә, концертларда катнаша. «Өзелгәнсең сиреньнән», «Бер генә минутка» кебек җырларны кем генә җырламады. Чөнки сатып бирмәдем. Җырлансын, җыр җырланырга тиеш ул.

Җырны бит аны акча эшләп алыйм әле дип язып булмый. Шигырьне укыганда күңелгә көй килә икән, җыр булачак. Юк икән, үзеңне күпме интектерсәң дә, музыка язылмый. Җырлар языла әле, куәс бар. Хәзер инде репертуарында күпчелеге минем җырлар булган артистлар да шактый. Ришат Фазлыйәхмәтов, мәсәлән, Зөлфирә Шәйдуллина... Күп инде алар. Җырың халык арасында танылып, шуның әҗерен дә күрсәң, икеләтә күңелле, әлбәттә. Ничек булса да, зарланмыйм. Холык андый түгел.

:: Кызыгыз Чулпанга, эстрада синең урының түгел, дип әйткәнсез икән, сәбәбе нәрсәдә?

– Чулпан бервакытта да, җырчы булам, димәде. Ул аңа хобби дип карады, үзе өчен генә ике диск туплап чыгарды. Тавышы бик көчле булмаса да, үзенчәлекле. Җырлауның хобби икәнен аңлагач, Мәдәният институтында укыган вакытта ук юридик белем дә алды. Хәзер гаиләсе белән Мәскәүдә яшиләр, ике бала үстерәләр. Дөрес, аны хәзер дә туйларга, бәйрәмнәргә җырларга чакыралар. Ул бармый. «Әти, минем өчен гаилә – беренче урында», – ди.

:: Җырчы хатыны булу авырмы?

– Акыллы – атын, юләр хатынын мактар, дисәләр дә, мин хатынны мактыйм әле. Хатыннан бик уңдым. Ул – тормышымда да, иҗатта да таянычым. 1988–1990 нчы елларда икешәр капчык хат килә иде. Аларны хатыным белән бергә укыдык. Анда нәрсә генә юк: сине генә яратам, синнән бала табасым килә, тагын әллә нәрсәләр. Гаебем булмагач, курыкмадым. Без, гомумән, бервакытта да бер-беребездән көнләшмәдек. Ике арада һәрвакыт ышаныч булды, хәзер дә шулай. Бәлки, ул көнләшкәндер, әмма бервакытта да миңа сиздермәде. Иң кызыгы: бер авылда яшәп, бер мәктәптә укысак та, вакыты җиткәнче без бер-беребезне белмәдек. Без танышканда, аның егете бар иде. «Улмы, минме?» – дип, үзеннән сорадым да, «Син», – дигәч,

егете белән «разборка»га киттем. Аннары да ике ел озаттым әле мин аны. Әнкәйләргә кайтып: «Бәхет эзләргә читкә китәм», – дип әйткәч, «Өйләнсәң генә китәсең», – дигән шарт куйдылар. Өйләнештек тә Чиләбе өлкәсенә чыгып киттек. 9 айдан әйләнеп кайттык без. Буа шикәр заводына эшкә урнаштым, концертлар куя башладым. Бер кешедә дә булмаган җыр җырлыйсы килде дә авылдашым, гомере буе агроном булып эшләгән Рәшит Сабиров шигыренә «Ява карлар» дигән җыр яздым. Минем турыда «автор-башкаручы» дигән сүз китте. 1987 елда Буага концерт куярга Илһам Шакиров килде. Ул, мине концертына чакырып, ике җыр җырлатты. Аның командасында Володя Лапшин, Ганс абый Сәйфуллин бар иде, болар мине эләктереп алдылар инде. Икенче көнне Буа кунакханәсендә 18 җыр яздык. Шуннан соң кассета чыкты. Кайсы базарга барма, шул кассетаны әйләндерәләр иде.

Ул вакытта Илһам абыйлар, Әлфия апалар халык арасында булдылар. Авылларда талантлырак яшьләрне очратсалар, ярдәм итәргә тырышалар иде. Әлфия апа Авзалова Буага килгәч, аңа «Хуш инде» җырын бирдем. «Хуш инде», «Бәрәңге чәчәге» җырлары Илдар Юзеев сүзләренә язылган. «Бәрәңге чәчәге»н мин «Татарстан яшьләре» оештырган патриотик җырлар конкурсына җибәргән идем. Жюрида Илдар Юзеев та булган. «Монда хәзер һәрберсе минем сүзләргә көй яза башлады», – дигән дә, минем хатны карап та тормыйча, читкә алып куйган. Аннан соң без аның белән күрештек, шигырьләрен дә тәкъдим итеп карады, әмма башка җыр язылмады инде.

:: Халыкта, Салават белән эшли башлап, Фирзәр арткы планда калды, дигән фикер дә бар. Килешәсезме?

– Иң башта Салават миннән автограф алып китте әле ул. «Авылга кайттым, иң бәхетле кеше мин идем», – дип сөйләде бу турыда соңрак. Аннары инде Чаллыга үзе килде. Ә минем Буада яшәгән вакытлар. Концертлар күп, администраторлар өчәү, дүртәү булды. Сизәм инде, алдыйлар. Шуннан кирәк чакта гына чыгып керермен дип, концерт эшчәнлеген туктаттым да Салаватка җырлар яза башладым. Соңгы елларда Салаватның концертларында да катнашам. Холык буенча миңа халык алдына чыгып басу да авырга килә. Шуңа арткы планда үземне күпкә рәхәтрәк хис итәм. Ә сәләт һәм аны күреп алган өчен әткәй белән әнкәйгә рәхмәт. Элек мәктәптә 6 гармунчы бар иде. Миңа да тальян алып бирделәр. Өйрәндем дә, хромкада уйныйсы килә башлады. Әткәй: «Сарай башын печән белән тутырсаң, алам», – диде. Биш чакрым ераклыктан «уфалла» арбасы белән абый, апа, мин ташыдык. Көнгә 3 әйләнгәч, тутырдык. Әти сүзендә торды, хромкалы итте. Ә 8 нче сыйныфта баян алып бирде. Шул ук көнне «Җиз кыңгырау моңнары»н өйрәндем. Минем авылга кайтуым – бер яктан аларга рәхмәт әйтү дә ул. Кеше кендек каны тамган җирдә генә бәхетле.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ӘҢГӘМӘ ТУЛЫСЫНЧА VATANTAT.RU САЙТЫНДА

8 декабрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Лилия Гыймазова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Ярдәм булырмы?

Колакларым начар ишетә, бил, үпкә белән проблемалар бар. Элек елга бер тапкыр шифаханәдә ял итү өчен юллама, колак аппараты бирәләр иде. Хәзер нишләп бирмиләр?

РИНАТ. Биектау

Россия Социаль фондының Татарстандагы бүлеге матбугат хезмәте:
– Ташламалы категория гражданнарына шифаханәдә дәвалану өчен юлламаны Социаль фондка яки күпфункцияле үзәккә гариза язып, 3 елга бер тапкыр алырга мөмкин. Юлламадан медицина күрсәтмәләре буенча шифаханә дәвалануы тәкъдим ителгән дәүләт социаль ярдәме алучылар файдалана ала. Мәсәлән, инвалид балалар һәм өлкәннәр.

Шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен түбәндәге документлар кирәк:
1. Гариза.
2. Дәвалау-профилактика учреждениесендә дәвалаучы табиб тарафыннан бирелгән N 070/у формасындагы белешмә.
3. Гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ (паспорт, инвалид балалар өчен туу турында таныклык). Гаризаны вәкил аша тапшырган очракта вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ та кирәк була.

N 070/у формасындагы белешмәне рәсмиләштерү өчен гражданга яшәү урыны буенча сырхауханәгә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Шифаханәдә дәвалану өчен күрсәтмәләр булган очракта дәвалаучы табиб, юлламаны алу өчен, N 070/у формасындагы белешмә рәсмиләштерәчәк.

Автобус нигә туктамый?

Биектауга Казаннан 91 нче номерлы автобус йөри. Тик ул иртән Биектауда бөтен тукталышларда да туктамый. Нәтиҗәдә үзәккә кадәр өч чакрымлап җәяү барырга туры килә. Безгә, пенсионерларга, йөрергә авыр. Хастаханә кебек кирәкле оешмалар шунда урнашкан бит.

Ринат МӨХӘРЛӘМОВ. Биектау

Редакциядән. Шәһәр транспортында хезмәт күрсәтү өчен Казан башкарма комитетының транспорт буенча комитеты җавап бирә. Шуңа күрә шәһәр мэриясенең матбугат хезмәте белән элемтәгә кердек. «Бу очракта газета укучыга тәгаен җавап бирү авыр. Автобус йөртүчене система аша тикшерү өчен, тукталышны узып киткән автобусның дәүләт номеры, көне һәм вакыты турында мәгълүмат кирәк. Җәмәгать транспорты эшенә бәйле кимчелекләр турында хәбәр иткәндә, әнә шул хакта да истә тотсагыз иде», – дип аңлаттылар матбугат хезмәтендә.

Ник котламыйлар?

20 октябрьдә чыккан газетадагы «Халык авазы»нда «Әбине котламыйлармыни?» дигән сораугa җавап чыкты. Миңа да сентябрьдә 90 яшь тулды. Трай тибеп йөргән кеше түгел мин. 64 ел стажым бар. 33 ел Совет армиясендә хезмәт иттем. 31 ел Чаллының 34 нче мәктәбендә хәрби җитәкче булдым, аннан тормыш иминлеге нигезләре дәресләрен алып бардым. Бик күп грамоталарым, 17 медалем бар. Хәрби комиссариат та, ветераннар советы да, мәгариф идарәсе дә котламады. Администрациягә шалтыраткан идем, 90 яшьлекләрне котламыйбыз, 95, 100 яшьлекләрне генә котлыйбыз, диделәр.

Васил ВӘГЫЙЗОВ. Чаллы

Чаллы хакимиятенең мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы Римма Мөхәммәтҗанова:
– Вәгыйзов Васил Вәгыйз улы Чаллының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 34 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»ндә тормыш иминлеге нигезләре укытучысы булып эшләгән.

Быел 18 сентябрьдә мәктәп хезмәткәрләре – директор, тәрбия эше буенча директор урынбасары, тәрбия буенча директор киңәшчесе, технология укытучылары Васил Вәгыйзовичны 90 яшьлек юбилее белән котладылар, аңа истәлекле бүләкләр һәм азык-төлек җыелмасы тапшырдылар.

Әлбәттә, туган көн булгач, һәрберебез күп бүләк өмет итә. Васил Вәгыйзовичны мәгариф идарәсе котлады, хәрби комиссариат өчен җавап бирә алмыйм, Чаллыдагы район хакимиятләре исә Бөек Ватан сугышы ветераннарын гына котлый.

Акча артамы?

Киләсе елга икенче балага ана капиталын 834 мең сумга кадәр арттыралар дип ишеттек. Безнең дә сертификат бар. Моннан берничә ел элек алынган, суммасы да ул кадәр зур түгел. Киләсе елга безнең акча артамы? Күпмегә?

НАИЛӘ. Казан

Россия Социаль фондының Татарстандагы бүлеге матбугат хезмәте:
– 1 февральдә Социаль фонд әлеге сертификаттан файдаланмаган барлык гаиләләргә ана капиталы суммасын арттырачак. Сертификатта акчаның бер өлешен саклап калган ата-аналар да 7,5 процент индексация алачак. Кулланылмаган сумма никадәр зуррак булса, индексациядән соң өстәмә шулкадәр югарырак булачак. Әлегә кадәр сертификатны бөтенләй кулланмаган гаиләләр өчен сумма 44 мең сумга артачак. Әгәр икенче балага ана капиталы арттырылган һәм беренче чыгымнар да булмаган икән, ул 58 мең сум тәшкил итәчәк. Ана капиталының бер өлешен саклап калган ата-аналар да ике айдан соң индексациягә өметләнә ала. Әгәр барлык чыгымнардан соң гаиләдә, әйтик, 375 мең сум калган булса, нәкъ менә шушы сумма февраль аенда 7,5 процентка артачак. Нәтиҗәдә гаиләнең акчасы 403 мең сум булачак.

Укучы сүзе

СӘРИЯ МИФТАХОВАның «КЕСӘ КАЛЫНГА ТҮГЕЛ...» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

15 мең сум пенсия алган кеше каян алып бирсен 38 мең, бөтенләй авыл халкын мыскыл итәләр. Аңа яшәргә дә кирәктер бит, әле ай саен фатир өчен түлисе, даруын аласы бар.

Асия ГАНИЕВА

***

Авыл халкы куркак, басым астында бирә. Яшисе бар бит, кемдә кем шундый зур акча бирсен? Ул акча юк та.

Дания ГАЛИЕВА

ГӨЛСИНӘ ХӘБИБУЛЛИНАның «СЫЕРСЫЗ ЯШӘП БУЛМАС» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Барысы да бик җәл, мин инде бройлер тавыклар өчен дә кайгырып, төннәрен шуларны уйлап елап ятам. Мин шулай булып туганмын, бернишләп тә булмый. Йомырка сала торганнары инде аның минем аркада картаеп үлеп бара. Ярый әле мал-туар асрамыйбыз хәзер, мин бөтенләй үләр идем аннан.

Клара ГАФУРЬЯНОВА

***

Безнең якларда элек олы кешеләр әйтә торган иде: һәркемгә дә килми андый бәхет – берьюлы хатыннан, ипи миченнән һәм әйбәт сыердан уңу. Мәрхүм әни олыгайгач, үзенә дә уңайсыз булыр дип, абый-апалар белән сыерны бетерергә уйладык. Ул чем кара төстәге сыер шундый акыллы иде, көтүдән кайтып капка төбендә сабыр гына басып торуы истә, бер зыян иткәне хәтердә калмаган. Әни соңгы тапкыр савып абзардан чыгып киткәндә шундый авыр булды. Әнинең – сыерга, сыерның әнигә карап торганы. Кара сыер күргән саен әнинең акыллы сыеры искә төшә.

Рәлиф СӘЛАХОВ

Ләйсән САФИНА әзерләде

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 N 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче ярты еллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язЫл

4–14 декабрь –
ташламалы бәядән язылу көннәре

П2435 (җомга) >> ~~571 сум 98 тиен~~ **497 сум 34 тиен**

П2409 (сиш., чәрш., җомга) >> ~~1255 сум 86 тиен~~ **1086 сум 18 тиен**

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана.
7 декабрьдә уйнатылачак бүләк –
АЛЬБИНА ФАЗЛЫЕВАдан ЯУЛЫК

Бу атна җиңүчесе – Казаннан Нәфидә Сиражиева. Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуыгызны үтенәбез!

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акциянең оештыручысы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

Беләсең килсә...

1 Шәүкәт Галиевнең чын фамилиясе нинди?
а) Төхфәтуллин;
б) Гатауллин;
в) Һидиятуллин.

2 960 килограммлы кырпы балыгына һәйкәл кайда куелган?
а) Лаешта;
б) Тәтештә;
в) Кама Тамагында.

3 Үрмәкүчнең ничә тәпие бар?
а) 6;
б) 8;
в) 10.

4 Колливубл нәрсә ул?
а) каллиграфия жанры;
б) фил токымы;
в) эч быгырдау.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. б); 4. в).



Әз-мәз мәзәк

***

Смартфоннар уйлап табылганчы, шоферлар машина йөрткәндә нәрсәгә карап йөргәннәр икән?

***

Гаилә бюджетын хатыным белән бергә алып барабыз. Кереме минем өстә, чыгымы – хатында.

***

– Минем чыгышым вакытында залдан чыгып китмәгән бердәнбер кеше сез булдыгыз, докладымны ахырга кадәр тыңлаганыгыз өчен рәхмәт!
– Чыгып китә алмадым, чөнки миңа сездән соң чыгыш ясыйсы.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: намаз, Ява, сәрән, итек, Лаеш, Биг, так, Сид, акыру, ач, тишә, киная, тузу, тиңләү, ир, чия, на, ил, ләм, кургаш, Лоа, кесә, үзәк, Пыяла.

Вертикаль: бурсык, чиркәү, Нәби, Итил, ар, Гөлдания, Иркә, мәл, чаң, Гек, ана, ял, ас, ат, шәп, иш, китү, ят, танышу, Лилия, Вена, Рәзинә, ак, кабу, урамда.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 360

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+